Школьный учебник
«Татарский язык»

Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ



4 класс

издательство
«Татармультфильм»

## Тартым кушымчалары



| | |
|---|---|
| минем | **-м, -ым/-ем** |
| синең | **-ң, -ың/-ең** |
| аның | **-сы/-се, -ы/-е** |



# Аффиксы принадлежности

| | |
|---|---|
| безнең | **-быз/-без, -ыбыз/-ебез** |
| сезнең | **-гыз/-гез, -ыгыз/-егез** |
| аларның | **-лары/-ләре** |





Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## ДҮРТЕНЧЕ СЫЙНЫФ

БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(ТАТАР ТЕЛЕН БАШЛАП ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)

ДӘРЕСЛЕК Е.И. ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНӘ

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2024

УДК 811.512.145(075.2)
ББК 81.632.3я71
Х18

## Условные обозначения

Начало урока

Запомни!

Вспомни!

Произноси правильно!

Работа в парах

Работа в группах

Творческая работа

Инсценирование

Ситуативные упражнения

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 4 класс: учебник для образовательных организаций начального общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А Гиниятуллина. — Казань: Татармультфильм, 2024. — 140 с.: ил.
ISBN 978-5-906508-36-2.

**ISBN 978-5-906508-36-2**

**УДК 811.512.145(075.2)**
**ББК 81.632.3я71**

© Издательство «Татармультфильм», 2024
© Художественное оформление.
Издательство «Татармультфильм», 2024
Все права защищены.




Кадерле укучыбыз!

Менә тагын яңа уку елы башланды. Син дүртенче ел татар теле өйрәнәсең. Син инде татарча укый, яза беләсең, иптәшләрең белән татарча сөйләшә аласың. Яңа уку елы котлы булсын! Сиңа уңышлар телибез!

# ЯҢА УКУ ЕЛЫ КОТЛЫ БУЛСЫН!

## 1–2 нче дәресләр

1. Внимательно рассмотри рисунок. Кого ты видишь? Как назовёшь рисунок?




2. **Исеңдә калдыр! Запомни!**

**яңá укý елы́** — новый учебный год
**укý** — учёба
**башланá** — начинается
**котлы́йбыз** — поздравляем
**уңышлáр** — успехи

3. Прочитай текст. Перескажи его содержание.

Бүген зур бәйрәм — 1 нче сентябрь. 1 нче сентябрьдә яңа уку елы башлана. Без мәктәпкә барабыз. Мәктәптә без укытучыларны котлыйбыз.

**4. Исеңә төшер! Вспомни!**

**кем?** (кто?) — син, сез
**ке́мне?** (кого?) — сине, сезне
**ке́мгә?** (кому?) — сиңа, сезгә

**5.** Научись поздравлять своих учителей с праздником.




**6.** Тәрҗемә ит (переведи).

1) Яңа уку елы башлана. — … .
Мәктәптә уку башлана. — … .
Укучылар мәктәпкә баралар. — … .

2) Сезне котлыйм. — … .
Сезне бәйрәм белән котлыйм! — … .
Яңа уку елы белән котлыйм! — … .
Бәйрәм белән котлыйм! — … !

**7.** Какие комплименты говорят девочки друг другу?



— Син бүген бик матур!
— … .
— Синең көлмәгең матур!
— … .



**8.** Прочитай диалог. Поговорите друг с другом.

— Марат, син кая барасың?
— Мәктәпкә барам.
— Кем белән барасың?
— Саша белән барам.
— Ә син кая барасың?
— Мин стадионга барам.

## 3–4 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен тап.

әйе

юк

кирәк

бу

түгел

кирәкми

**2.** Уку-язу әсбаплары исемнәрен дөрес әйтергә (правильно произносить) һәм язарга өйрән, алар белән җөмләләр төзе.








**3. Исеңә төшер!**

Частица **-мы/-ме** в конце слова выражает вопрос: **кита́пмы? дәфтә́рме? ба́рмы? кирә́кме?**

**4.** Используя названия учебных принадлежностей, поговорите друг с другом по образцу.

Образец:

а) — Бу дәфтәрме?
— Әйе, бу дәфтәр.

ә) — Бу дәфтәрме?
— Юк, бу дәфтәр түгел, бу блокнот.

б) — Бу дәфтәр яңамы?
— Әйе, бу дәфтәр яңа.

в) — Бу дәфтәр яңамы?
— Юк, бу дәфтәр яңа түгел.

**5. Исеңә төшер!**

**миңа́** — мне **синңа́** — тебе **аңа́** — ему (ей)

**6.** Дополни диалог. Поговорите с соседом по парте.

– Сиңа дәфтәр кирәкме?
– … .
– Сиңа нинди дәфтәр кирәк? Шакмаклы дәфтәрме? Сызыклы дәфтәрме?
– … .

**7.** Шигырьне укы, ошаса, ятла.



Һәр атнада җиде көн,
Җиде көн һәм җиде төн.
Портфельдә җиде әйбер,
Ул нинди әйберләр бел:




Карандаш һәм бетергеч,
Дәфтәр, каләм, киптергеч,
Бер агач пенал тагы
Һәм әлифба китабы.

Самуил Маршак

## 5–7 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

В татарском языке имя существительное при числительных употребляется в единственном числе: **өч алма, биш дәфтәр, дүрт карандаш.**

**2.** Җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз. Һәр җөмләгә сорау куй.

Үрнәк: Китап бар. Сумкада китап бар. Сумкада 3 китап бар. Минем сумкада 3 китап бар.

Җөмләләр: Дәфтәр бар. Пенал бар. Бетергеч бар.

**3.** Нокталар урынына (вместо точек) төшеп калган репликаларны яз, дустың белән сөйләш.

— … ?
— Юк, миңа дәфтәр кирәкми.
— Ә нәрсә кирәк?
— … .

**4.** Используя рисунки:

— попроси себе эти учебные принадлежности;
— сообщи, что тебе нужна тетрадь;
— узнай у друга, нужны ли ему эти учебные принадлежности.




**5.** **Исеңә төшер!**

мой(я) — **минéм** (китабым, күзлегем)
твой(я) — **синéң** (китабың, күзлегең)
его (её) — **аны́ң** (китабы, күзлеге)

В словах, оканчивающихся на **к**, **п**, при добавлении аффиксов **-ым/-ем**, **-ың/-ең**, **-ы/-е** звуки **[к]**, **[қ]** и **[п]** чередуются со звуками **[г]**, **[ғ]** и **[б]**:

күзле**к** — күзле**г**ем, күлмә**к** — күлмә**г**ем, урынды**к** — урынды**г**ым, ту**п** — ту**б**ым.

6. Рәсемнәр урынына тиешле сүзләрне куеп укы. Дустың белән сөйләш.

1) Бу минем . 2) Синең  бармы? Бар.
3) Синең  бармы? 4) Коляның  бармы?

7. Иптәшеңнән сора: аның нинди уку-язу әсбаплары бар?

8. **Исеңә төшер!**

**-лар/-ләр, -нар/-нәр** — аффиксы множественного числа (күплек сан):

китап — китап**ла́р**
дәфтәр — дәфтәр**лә́р**
урман — урман**на́р**
көн — көн**нә́р**

9. Диалогны репликалар өстәп укы. Иптәшең белән сөйләш.

— Исәнме, Оля!
— ... .
— Оля, синең сумкаң яңамы?
— Әйе, минем сумкам яңа, апам бүләк итте.
— ... ?
— Әйе, мин 10 яңа дәфтәр, 1 линейка алдым. Ә син?
— ... .



**10.** Как скажешь о том, что:

— тебе купили ручку, тетради, циркуль;
— твоя сестра подарила тебе сумку;
— у тебя в сумке 5 тетрадей, 2 книги;
— ты учишься в четвёртом классе;
— ты поздравил учителя с новым учебным годом?

## 8–9 нчы дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

В татарском языке 9 гласных и 28 согласных звуков.

Гласные [а] — [ә], [у] — [ү], [о̆] — [ө], [ы̆] — [э̆] — парные по твёрдости и мягкости, [и] — всегда мягкий звук. В татарском языке есть звуки, которых нет в русском. Это — [қ], [ғ], [w], [ң], [җ], [һ], [а°], [ә], [ү], [о̆], [ө], [ы̆], [э̆].

«Алты хәреф» белән мәкальләр өйрән!

**2.** Бу авазлар ничек әйтелә?

[а°] — огублённо
[қ] — твёрдо
[ғ] — твёрдо
[ы̆] — кратко
[э̆] — кратко
[о̆] — кратко

каты — [қа°ты̆́]
калын — [қа°лы̆́н]
чыга — [чы̆ға́]
авыл — [а°wы̆́л]
бетергеч — [бэ̆тэ̆ргэ́ч]
болын — [бо̆ло́н]

**3.** Ничек укыла?

е:
[йы̆] — елан
[йэ̆] — егет
[э̆] — беренче

я:
[йа°] — яза
[йә] — яшел

## 4. Исеңә төшер!

Буквы **к, г** обозначают по два звука:

**к** — [қ] — кара; [к] — кил

**г** — [ғ] — карга; [г] — гөл

## 5. Исеңә төшер!

В татарском языке буквы **о, ы, э** обозначают по два звука. В словах, заимствованных из русского языка, они произносятся дольше, чем в татарском:

[о̄рден], [вы̄шка], [шты̄к], [э̄таж].

В словах татарского языка они произносятся коротко:

[то̆р], [ы̆лы̆́с], [йо̆рт], [э̆т].

**6.** Сүзләрне таблицага яз.

Кыш, йокы, орден, оя, посылка, кино, эш, кырык, завод, болын, экран, флот, калын, радио, орлык, солдат, йорт, солы, озын, кыска, почта, эт, котлый.

| [о̄], [ы̄], [э̄] | [о̆], [ы̆], [э̆] |
| --- | --- |
| ... | ... |

## 7. Спроси у друга:

— сколько букв в татарском языке;
— сколько согласных, сколько гласных звуков;
— каких звуков нет в русском языке.

## 10–11 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**Сан.** Имя числительное

Имя числительное отвечает на вопросы:

**ни́чә?** — сколько? — биш, алты

**ни́чәнче?** — который (по счёту)? — бишенче, алтынчы



2. Саннарны тәртип буенча урнаштыр (расположи по порядку).

1) Бер, өч, ике, алты, дүрт, биш, җиде, ун, тугыз, сигез.

2) Унике, унбер, ундүрт, егерме, унбиш, унҗиде, унтугыз, унсигез, унөч, уналты.

3) Йөз унбер, йөз унбиш, йөз унөч, йөз унике, йөз унҗиде, йөз ундүрт, йөз уналты.

3. Саннарны сүз белән яз, җөмләләр төзе.

10, 20, 30, 40, 50, 60, 70, 80, 90, 100.
1000, 1917, 1999, 2021, 2023, 2050, 10000.

**4.** Попроси себе:

— 5 тетрадей;
— 2 линейки;
— 3 книги.

**5.** Скажи:

— сколько тебе лет;
— в какой школе ты учишься;
— в каком ряду ты сидишь;
— сколько мальчиков и девочек в классе;
— что тебе надо пять тетрадей в клетку и пять тетрадей в линейку.

**6.** Какой вопрос задашь, чтобы узнать:

— сколько лет Марату;
— в какой школе учится Марат;
— в каком классе учится Марат;
— в каком ряду сидит Марат;
— нужны ли Марату тетради, книги?

**7.** Мәсьәләне чиш.

Синең 6 дәфтәрең бар. Син 2 дәфтәреңне Алмазга бирдең. Ничә дәфтәрең калды?



## 12–14 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**чө́нки** — потому что
**шуңа́ күрә́** — поэтому

2. Сүзләрне дөрес укырга өйрән. Тәрҗемә ит.

[бӗтӗргә́ч], [кирәклә́], [һә́рwақы̆т], [сүндӗрә́м], [өстөнә́], [қәлә́м], [тәрти́п].

3. Текстны укы. Оляның эш урыны сиңа ошыймы?

### Эш урыны



Минем исемем — Оля. Мин дүртенче сыйныфта укыйм. Мин тәртип яратам, шуңа күрә эш урыным һәрвакыт чиста. Минем эш урыным — язу өстәле.

Өстәлдә кирәкле китаплар, дәфтәрләр генә бар. Өстәлгә каләм, линейка, бетергеч тә куям. Алар һәрвакыт кирәк. Өстәл өстенә ваза белән чәчәк куям, чөнки мин чәчәк яратам.

**4.** Бу сүзләр кергән җөмләләрне текстган табып укы. Аларның тәрҗемәсен беләсеңме?

| | | |
|---|---|---|
| тәртип | һәрвакыт | шуңа күрә |
| эш урыны | куям | чөнки |

**5.** Найди в тексте предложения о том, что:

— Оля учится в четвёртом классе;
— Оля любит порядок;
— Оля любит цветы;
— рабочее место Оли — письменный стол.

**6.** Рәсемгә кара һәм әйт: эш өстәлендә нәрсәләр артык (лишнее)?




**7.** Спроси у друга, нужны ли ему эти предметы.

**8.** Бу предметларның кайсы Оляның өстәлендә юк?

Көндәлек, китап, плеер, компьютер, төсле карандашлар, бетергеч, пенал, ваза, магнитофон, альбом, портфель, стакан.

**9.** Диалогларны укы. Дустың белән сөйләш.

а) — Синең эш урының бармы?
— Әйе, бар.
— Ул кайда?
— Бүлмәдә.

ә) — Өстәлең нинди чиста!
— Әйе, мин тәртип яратам.
— Ә сумкаң кайда?
— Урындыкта.

б) — Оля, миңа бетергеч бир әле.
— Ал.
— Ә кайда ул?
— Пеналда.

в) — Саша, син нишлисең?
— Дәрес әзерлим.
— Сиңа линейка кирәкме?
— Әйе, кирәк.

г) — Синең эш урынында нәрсәләр бар?
— Минем эш урынында өстәл, компьютер, лампа, китаплар бар.

**10.** Уйла һәм әйт: яхшы уку өчен кайсы сыйфатлар кирәк? Партадашың белән диалог төзе.

Тырыш, игътибарлы, ялкау, игътибарсыз, эшчән, тәртипле, тәртипсез.

**11.** Җөмләләрне төгәллә һәм дәфтәреңә яз. Аларга сорау куй.

1) Оля — тырыш укучы, шуңа күрә ... .
2) Сашаның өстәле һәрвакыт ... , чөнки ул тәртип ... .
3) Укучы дәрестә игътибарсыз, шуңа күрә ул ... .
4) Наташаны дуслары ярата, чөнки ул ... .

**12.** Узнай у друга:

— есть ли у него дома рабочее место;
— что есть у него на рабочем столе.

**13.** Бергәләп көлик.

Укытучы:
— Фәрит, математикадан өй эшен нигә эшләмәдең?
Укучы:
— Әти күзлек тапмады.



**күзлек** — очки
**тапмады** — не нашёл

## 15–16 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен исеңә төшер.

пример ? упражнение
задача ? контрольная работа
вопрос ? ответ

**2.** Составь словосочетания из слов в столбиках.

| | | |
|---|---|---|
| мисал | ? | чиштем |
| мәсьәлә | | бирдем |
| контроль эш | | яздым |
| җавап | | әйттем |
| сорау | | эшләдем |
| күнегү | | |
| диктант | | |

**3.** Диалогларны укы, дустың белән сөйләш.

а) — Оля, бу нинди дәрес?
— Бу — татар теле дәресе.
— Сез дәрестә нишлисез?
— Без укыйбыз, күнегү эшлибез, диктант язабыз.

ә) — Костя, бу нинди дәрес?
— Бу — математика дәресе.
— Сез дәрестә нишлисез?
— Без дәрестә мисал эшлибез, мәсьәлә чишәбез.

**4. Исеңдә калдыр!**

**хаталы́** — с ошибкой
**хатасы́з** — без ошибок
**матема́тика** — математика
**матема́тикадан** — по математике
**матема́тикадан контро́ль эш** — контрольная работа по математике
**матема́тика дәресендә́** — на уроке математики
**тата́р теле́** — татарский язык
**тата́р теленнә́н** — по татарскому языку
**тата́р теле́ дәресендә́** — на уроке татарского языка

**5.** Восстанови диалог. Поговорите с соседом по парте.

а) — … ?
— Мин математикадан дүртле алдым. Ә син?
— … .

ә) — … ?
— Без иртәгә диктант язабыз.

— Ничәнче дәрестә?

— … .

**6.** Спроси у друга:

— приготовил ли он домашнее задание;
— что задано на дом;
— какие оценки он получил сегодня;
— какие уроки ему нравятся.

## 17–19 нчы дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**Ни́шләмәде?** — Что не сделал?
Если действия не происходили, то говорят так:
я́з +**ма**+ды — **не** писал    чи́ш+**мә**+де — **не** решал
Мин я́з+ма+ды+м, чи́ш+мә+де+м.
Син я́з+ма+ды+ң, чи́ш+мә+де+ң.
Ул я́з+ма+ды, чи́ш+мә+де.

**2.** Җөмләләрне үрнәк буенча киңәйтеп (распространив) яз.

Үрнәк: Мин мәсьәлә чиштем. Мин бүген мәсьәлә чиштем. Мин бүген математика дәресендә мәсьәлә чиштем.

Җөмләләр: Мин мисал эшләдем. Мин диктант яздым. Мин мисал эшләмәдем.

**3.** Хикәяне укы һәм исем бир.



Бүген Алсуның кәефе юк. Өченче дәрестә математикадан контроль эш булды. Ә Алсу ике мисалны дөрес эшләмәде, мәсьәләне дә дөрес чишмәде. Кичә бик озак телевизор карады. Башта мультфильм, аннан соң кызыклы кино булды. Аннан дуслары килде. Алар белән бик күңелле булды. Кичә күңелле иде, ә бүген...

**кичә** — вчера
**булды** — было
**кәеф** — настроение
**аннан** — потом

**4.** Составьте вопросы к содержанию текста упражнения №3.

**5.** Бу җөмләләрнең кайсы текстта бар?

1) Бишенче дәрестә математикадан контроль эш булды. 2) Өченче дәрестә татар теленнән язма эш булды. 3) Өченче дәрестә математикадан контроль эш булды. 4) Ике мисалны дөрес эшләмәде. 5) Мәсьәләне дөрес чиште. 6) Мәсьәләне дөрес чишмәде. 7) Дуслар белән күңелле булды. 8) Алар белән бик күңелле

булды. 9) Кичә дә, бүген дә күңелле булды. 10) Кичә күңелле булды, ә бүген күңелсез.

**6.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1) Өченче дәрестә математикадан контроль эш булды. 2) Алсу мәсьәләне дөрес чишмәде. 3) Алсу ике мисалны дөрес эшләмәде. 4) Аннан соң дуслары килде. 5) Башта мультфильм, аннан кызыклы кино булды. 6) Алсу бик озак телевизор карады.

**7.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1) Татар теленнән контроль эш булды.
Математикадан контроль эш булды.
2) Алсу мисалны дөрес эшләде.
Алсу мисалны дөрес эшләмәде.
3) Алсу мәсьәләне дөрес чиште.
Алсу мәсьәләне дөрес чишмәде.

**8.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Өченче дәрестә ... . 2) Алсу ике мисалны ... һәм мәсьәләне ... . 3) Алсу бик озак ... . 4) Телевизордан башта ... , аннан соң ... . 5) Ул дәресләрен ... .

**9.** Расскажите друг другу содержание текста об Алсу.

**10.** Сообщи другу о том, что:

— сегодня у вас пять уроков;
— на втором уроке была контрольная работа по математике;
— во вторник вы писали диктант по татарскому языку;

— сегодня ты учишь стихотворение;
— он неправильно решил задачу.

**11.** Восстанови диалоги. Разыграйте их с соседом по парте.

1) — ... ?
— Бездә контроль эш булды.
— Кайсы предметтан?
— ... .

2) — ... ?
— Юк, мин дәрес әзерләмәдем.
— Нәрсә эшләдең?
— ... .
— Ни өчен эшләмәдең?
— ... .

## 20–21 нче дәресләр

**1.** Алсу турындагы хикәяне исеңә төшер. Иң яхшы сөйләүчегә конкурс! Сөйләүчегә бәя бирергә онытма!

| **Эчтәлекне ничек сөйли?** | **Сүзләрне ничек әйтә?** |
| --- | --- |
| Эчтәлекне дөрес сөйли. | Сүзләрне дөрес әйтә. |
| Эчтәлекне дөрес сөйләми. | Сүзләрне дөрес әйтми. |

**Ничек сөйли?**

Сәнгатьле сөйли.
Сәнгатьле сөйләми.

**2.** Представь, что Алсу не ленилась, готовила уроки. Изменится ли рассказ? Напиши его. Перескажи свой рассказ.

**3.** Беренче һәм икенче хикәядәге Алсуга кайсы сыйфатлар туры килә? Таблицаны тутыр.

Терәк (опорные) сүзләр: тырыш, ялкау, игътибарлы, игътибарсыз, эшчән, уйнарга ярата, укырга ярата, акыллы, вакытны дөрес файдаланмый (не использует).

| Беренче хикәядәге Алсу | Икенче хикәядәге Алсу |
|---|---|
| ... | ... |

**4.** Кайсы диалог текстка туры килә?

1) — Кызлар, әйдә безгә килегез.

— Сездә нишлибез?

— Мультфильм карыйбыз! Аннан соң кызыклы кино була.

— Кино да карыйбыз.

2) — Алсу, әйдә урамга чыгабыз.

— Юк, чыкмыйм, эшем бар.

— Нишлисең?

— Иртәгә математикадан контроль эш була. Әзерләнәм.

**5.** Скажи, что:

— завтра у вас контрольная работа по математике;

— сегодня вы писали диктант по русскому языку;

— ты написал диктант без ошибок.

**6.** Восстанови диалоги. Разыграйте их с соседом по парте.

1) — ... ?
— Әйе, контроль эш булды.
— Ничә мисал бар иде?
— ... .
— ... ?
— Әйе, мәсьәлә дә бар иде.
— Ничә мәсьәлә?
— ... .



2) — ... ?
— Әйе, контроль эш булды.
— Контроль эшне эшләдеңме?
— ... .
— Ә мәсьәләне чиштеңме?
— ... .

## 22–23 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Спроси у соседа по парте:

— какие учебные принадлежности у него есть;
— как прошло 1 сентября в школе;
— какие оценки он уже получил;
— какие уроки ему нравятся;
— была ли у них контрольная работа;
— писали ли они диктант;
— что они сегодня делали на уроке математики (татарского языка, русского языка);
— есть ли у него рабочее место дома.

**2.** Сораулар буенча партадашың белән сөйләш.

1) Син ничәнче мәктәптә укыйсың? 2) Син ничәнче сыйныфта укыйсың? 3) Син нинди телләр өйрәнәсең? 4) Татарча яхшы беләсеңме? 5) Татар теле дәресендә син нәрсәләр эшлисең? 6) Математика дәресендә нәрсә эшлисең? 7) Рәсем һәм җыр дәресләрендә нишлисез?

**3.** Какие вопросы ты задашь, чтобы получить такие ответы?

— ... ?
— Юк, без диктант яздык.
— ... ?
— Мин дүртле алдым.
— ... ?
— Ике хатам бар.
— ... ?
— Юк, урамга чыкмыйм, мин дәрес әзерлим.

**4.** Восстанови диалог. Поговорите с соседом по парте.

— Мин математикадан дүртле алдым. Ә син?
— ... .
— Татар теленнән диктант яздыгызмы?
— ... .

**5.** Сообщи другу о том, что:

— ты учишься в четвёртом классе;
— в семье вас четыре человека;
— ты живёшь на седьмом этаже.

# МИНЕМ ТУГАН ИЛЕМ

## 24–25 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәләрен исеңә төшер. Дәфтәреңә яз.

туган як
туган ил
башкала
дәүләт
милләт
тел

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

туган
елга
Агыйдел
Бөгелмә

? [г] [ғ]

киң
күл
кыр
төлке

? [к] [қ]

**3.** Подбери к словам пару.

усал
зур
хәйләкәр
озын
матур
биек

?

елга
төлке
бүре
тау
авыл
шәһәр

**4.** Скажи данные слова во множественном числе.

Урман, кыр, күл, поши, аю, бүре, төлке, елга, шәһәр, тиен, куян, керпе.



**5.** Текстны укы.

### Россия — минем туган илем

Мин Россиядә яшим. Ул — зур, бай дәүләт. Аның башкаласы — Мәскәү. Россиядә шәһәрләр бик күп. Иң зур шәһәрләр: Мәскәү, Санкт-Петербург, Новосибирск, Екатеринбург, Түбән Новгород, Казан, Уфа, Самара.

Россиянең табигате бик матур. Анда куе урманнар, киң кырлар, күлләр, биек таулар да бар. Урманнарда пошилар, аюлар, көчле юлбарыслар, усал бүреләр, хәйләкәр төлкеләр яшиләр.

Мин туган илемне бик яратам!

**дәүләт** — государство
**башкала** — столица
**поши** — лось
**юлбарыс** — тигр
**куе** — густой

**6.** Найди в тексте «Россия — минем туган илем» слова, отвечающие на вопрос **нинди?**.

**7.** Найди к каждой группе обобщающее слово.

1) Лена, Идел, Енисей, Агыйдел — ... .
2) Казан, Яр Чаллы, Әлмәт — ... .
3) Мәскәү, Санкт-Петербург, Владивосток — ... .

**8.** Найди в тексте предложения, соответствующие пунктам плана. Расскажи содержание текста другу.

1) Минем туган илем.
2) Россия шәһәрләре.
3) Россия табигате.

## 26–27 нче дәресләр

**1.** Конкурс на лучшего рассказчика текста «Туган илем — Россия».



**2.** Спроси у друга:

— где он живёт;
— какие города есть в России;
— есть ли в России леса;
— какие реки есть в России;
— какие животные обитают в лесах Татарстана.

**3.** Диалогны репликалар өстәп укы. Иптәшең белән сөйләш.

— Саша, син кайда яшисең?
— ... .

— Россиянең башкаласы нинди шәһәр?
— ... .
— Россиянең табигате турында сөйлә әле.
— ... .



**4.** Диалогны укы. Үзара сөйләшегез.

— Аня, син сәяхәт итәргә яратасыңмы?
— Әлбәттә. Без җәй көне Мәскәүгә бардык.
— Мин дә Мәскәүгә барырга яратам.
— Сиңа Мәскәү ошадымы?
— Бик ошады. Мәскәү — зур шәһәр. Без Кызыл мәйданда йөрдек. Минин һәм Пожарский һәйкәле, Василий Блаженный соборы, Мавзолей янында булдык.

**5.** Кызыл мәйдан турында (о чём) сөйләргә өйрән.

## 28–29 нчы дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**Россиянең гербы** — герб России
**Россия гербында** — на гербе России

**Татарстанның флагы** — флаг Татарстана
**Татарстан флагында** — на флаге Татарстана

**бөркет** — орёл
**ике башлы бөркет** — двуглавый орёл

**канатлы барс** — крылатый барс

**2.** Текстны укы. Россия дәүләте һәм Татарстан Республикасы символлары турында сөйләргә өйрән.










Гербтагы Барс ни сөйли?

Татарстан Республикасы Россия дәүләтендә урнашкан. Россиянең дә, Татарстанның да үз символлары бар.

Россия флагында ак, зәңгәр, кызыл төсләр бар. Ә гербына ике башлы бөркет

сурәтләнгән. Татарстан Республикасының флагында яшел, ак, кызыл төсләр бар. Аның гербында канатлы барс сурәтләнгән. Ул — Татарстанда яшәүче халыкларның яклаучысы.

Гербның авторы — рәссам Риф Фәхретдинов. Татарстан Республикасы гимнының авторы — композитор Рөстәм Яхин, ә текстының авторы — Рамазан Байтимеров.

**3.** Татарстан Республикасы гимнының татарча һәм русча вариантларын өйрәнегез.

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живёт в согласии наш народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!

*Музыка Рустема Яхина,*
*слова Рамазана Байтимерова,*
*перевод на русский язык*
*Филиппа Пираева*

Татарстан гимнын тыңла!

## 30–32 нче дәресләр

**1.** Текстны укы.

### Туган җирем — Татарстан

Татарстан Республикасы Россия дәүләтендә урнашкан. Татарстан — зур һәм бай республика. Татарстанда матур шәһәрләр һәм авыллар бик күп. Татарстанда татарлар, руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар, башкортлар, азәрбайҗаннар, мордвалар, белоруслар, украиннар һәм башка милләт вәкилләре яши. Бу халыклар дус һәм тату яшиләр.



**2.** Сорауларга җавап бир.

— Татарстан Республикасы кайда урнашкан?
— Татарстанда нинди милләт вәкилләре яши?
— Алар ничек яшиләр?

**3.** Сораулар ярдәмендә диалоглар төзеп, дустың белән сөйләш.

1) Сезнең сыйныфта нинди милләт укучылары укый?
2) Сез нинди телләр өйрәнәсез?
3) Син татарча ничек сөйләшәсең?

**4.** Сораулар буенча сөйләргә өйрән.

1) Син нинди республикада яшисең?
2) Син нинди шәһәрдә (авылда) яшисең?
3) Сезнең шәһәрдә (авылда) нинди милләт вәкилләре яши?
4) Бу милләтләр үзара ничек яши?
5) Син нинди телләр өйрәнәсең?

**5.** 4 нче күнегү эчтәлеге буенча үзара сөйләшегез.

**6.** Как скажешь о том, что:

— в Татарстане проживают представители разных национальностей;
— они живут дружно;
— ты изучаешь русский, татарский, английский языки;
— русский язык — твой родной язык;
— ты хорошо разговариваешь на татарском и английском языках?

**7.** Шигырьне укы. Шагыйрь сиңа нинди киңәш (совет) бирә?

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Шәйхи Маннур

**затлы** — благородный (достойный)

Татарстан-дагы милләтләр турында беләсең киләме?

## 33–35 нче дәресләр



**1.** Бу сүзләрне онытма! Алар сиңа текстны аңларга ярдәм итәр.

**башкала** — столица
**мәчет** — мечеть
**манара** — башня (минарет)

**2.** Тәрҗемәне истә калдыр.

Казанский Кремль — Казан Кремле
Башня Сююмбике — Сөембикә манарасы
Мечеть Кул Шариф — Кол Шәриф мәчете
Благовещенский собор — Благовещение соборы

**3.** 2 нче күнегүдә бирелгән сүзтезмәләр белән җөмләләр уйла.

Казан буйлап сәяхәт

**4.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

башкала [бa°шқалá], шәһәр [шәһә́р], Кол Шәриф [қо̆л шәри́ф], Сөембикә [сөйөмбикә́], манара [ма°нарá], халык [ха°лы̆́қ].

**5.** Текстны укы. Текст нәрсә турында (о чём)? Аңа исем бир.

Казан — Татарстанның башкаласы. Күптән түгел без Казанга экскурсиягә бардык. Казан — матур шәһәр. Без Казан Кремлендә булдык. Анда Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы бар. Сөембикә манарасы җиде катлы. Манара очында алтын ай бар.

Казанда театрлар, музейлар бик күп. Татарстанның Милли музее Кремль янында урнашкан. Без музейда булдык. Безгә музей бик ошады.

Казанда яңа спорт корылмалары күп. Анда дөньякүләм спорт ярышлары була.

**җиде катлы** — семиярусный
**очында** — на конце (на верхушке)
**спорт корылмасы** — спортивное сооружение
**дөньякүләм спорт ярышлары** — всемирные спортивные соревнования

**6.** Ноктлалар урынына тиешле кушымчалар куй, күчереп яз.

1) Без Казан Кремле яны... булдык.
Без Казан Кремле яны... килдек.
Без Казан Кремле яны... киттек.
2) Без Сөембикә манарасы... булдык.
Без Сөембикә манарасы... мендек.
Без Сөембикә манарасы... төштек.

**7.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1) Кремльдә Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы бар. 2) Казан — бик матур шәһәр. 3) Күптән түгел без Казанга экскурсиягә бардык. 4) Татарстанның Милли музее Кремль янында урнашкан. 5) Без музейда булдык. 6) Казанда яңа спорт корылмалары күп.

**8.** Рассмотри рисунки и скажи, какие достопримечательности изображены.








9. Диалогны сәхнәләштерегез.



— Марат, син җәй көне кая бардың?

— Казанга бардым.

— Кол Шәриф мәчетен күрдеңме?

— Әйе, без Кол Шәриф мәчетен күрдек.

— Ул кайда урнашкан?

— Ул Кремльдә урнашкан. Без Благовещение соборына да кердек.

— Ә ул кайда урнашкан?

— Ул да Кремльдә урнашкан.



10. Поговорите с другом.

— Россия флагында нинди төсләр бар?

— Россия флагында ак, зәңгәр, кызыл төсләр бар.

— Татарстан флагында нинди төсләр бар?

— Татарстан флагында зәңгәр, яшел, ак төсләр бар.

11. Как скажешь о том, что:

— в Татарстане проживают представители разных национальностей;

— они живут дружно;

— русский язык — твой родной язык;

— ты и по-татарски, и по-английски хорошо разговариваешь?

## 36–37 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Спроси у друга:

— какие города России он знает;
— знает ли он символику России;
— какие города в Татарстане он знает;
— знает ли он символику Татарстана;
— есть ли у них в городе музеи, театры.

**2.** Составь диалоги по содержанию упражнения №1. Поговорите друг с другом.

**3.** Дополни диалог вопросами и ответами.

— … ?
— Без Татарстанда яшибез.
— Татарстанның башкаласы нинди шәһәр?
— … .
— … ?
— Әйе, Казан зур, матур шәһәр.
— … ?
— Татарстанда татарлар, руслар, башкортлар һәм башка милләтләр бар.
— … ?
— Алар дус һәм тату яшиләр.
— Син нинди телләр өйрәнәсең?
— … .

**4.** «Казан — Татарстанның башкаласы» дигән кичәдә син нәрсәләр сөйләр идең? Дәфтәреңә яз.

**5.** Кроссвордны чиш. Вертикаль баганадагы сүзне әйт.




1) Татарстандагы нефтьчеләр шәһәре.
2) «КАМАЗ» машиналары кайда чыга?
3) Атаклы татар шагыйре.
4) Татарстан гербында сурәтләнгән хайван.
5) Вятка елгасының татарча исеме.
6) Казандагы тарихи манара.
7) Милли баш киеме.
8) Татарстан башкаласы.
9) Татарстан гимны музыкасының авторы.

**6.** Позови друга посетить музей. Убеди его в том, что там очень интересно.

**7.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куй.

Мин Казан шәһ...р...ндә ...шим. Ә дустым Азат Әлм...т шәһәр...ндә ...ши. Аның әтисе — нефтьч... . Азат җәй к...н... Каз...нга килә. Мин аны к...тәм.

**8.** 7 нче күнегүнең эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**9.** Спроси у друга:
— в какой стране он живёт;
— в какой республике он живёт.

## 38–39 нчы дәресләр



**1.** Шигырьне укы. Нәрсә ул табигать?

### Табигать китабы

Әйдәгез урманга
Һәм кырга —
Табигать китабын
Укырга.
Бу китап гаять зур,
Гаять бай.
Анда бар:
Җир, су, күк,
Кояш, ай.
Йөрибез урманда,
Аланда,
Җәнлекләр,
Кош-кортлар
Күп анда...

Җәвад Тәрҗеманов

**табигать** — природа
**алан** — поляна
**ай** — месяц
**гаять** — очень
**кош-корт** — птицы
**күк** — небо

**2.** Как скажете о том, что:

— природа это — земля, вода, небо, лес, солнце, луна, животные, птицы;

— природа очень богатая;

— ты любишь природу?

**3.** Текстны укы. Елның нинди фасыллары бар?

**Елның дүрт фасылы**

Ел дүрт фасылга бүленә: яз, җәй, көз, кыш.
Яз айлары: март, апрель, май.
Җәй айлары: июнь, июль, август.
Көз айлары: сентябрь, октябрь, ноябрь.
Кыш айлары: декабрь, гыйнвар, февраль.

Габдулла Тукайдан

**ел фасылы** — время года

**4.** Рәсемнәр кайсы ел фасылына туры килә?






**5.** Бу шигырьләр нинди ел фасылларына, кайсы рәсемгә туры килә? Шигырьләрне сәнгатьле укырга өйрән.





1) Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана, —
Бу кайчак була?

2) Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран, —
Бу кайчак, туган?

Габдулла Тукай



3) Гөрләвек ага,
Кояш елмая.
Торналар үтте
Тезелеп бая.



4) Матур җәй, кил безгә,
Кил, кил тизрәк син безгә,
Гөлләр белән бизәп җирне,
Чәчәкләр бир син безгә!

Бари Рәхмәт

**6.** **Запомни:**

**җәен** — летом
**көзен** — осенью
**кышын** — зимой
**язын** — весной

**7.** Используя слова *җәен, көзен, кышын, язын,* ответь на вопросы:

1) Кайчан яңгыр ява?
2) Кайчан кар ява?
3) Кайчан көн эссе була?
4) Кайчан яфраклар коела?

**8.** Поговорите с другом:

— Син җәйне яратасыңмы?

— Әйе, яратам.

— Ни өчен яратасың?

— Чөнки җәй көне көннәр җылы була, каникуллар башлана.

## 40–41 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**Үткән заман хикәя фигыль**
Прошедшее время глагола

К основам глагола, оканчивающимся на гласные и звонкие согласные звуки, в прошедшем времени присоединяются аффиксы **-ды/-де**: аша+**ды́**, кил+**де́**.

К основам глагола, оканчивающимся на глухие согласные, в прошедшем времени присоединяются аффиксы **-ты/-те**: кайт+**ты́**, кит+**те́**.

**2.** Җөмләләрне укы. Сүзләрне таблицага яз.

Көз **җитте**. Көннәр салкын. Салкын җил **исә**. Кошлар җылы якларга **китә**. Көннәр **кыскарды**, төннәр **озынайды**. Мәктәптә укулар **башланды**.

| Үткән заман хикәя фигыль | Хәзерге заман хикәя фигыль |
| --- | --- |
| ... | ... |

**3.** Диалогны укы. Партадашың белән сөйләш.

— Без кичә урманга бардык.

— Урманда нишләдегез?

— Без яфраклар җыйдык.

— Сез бүген урманга барасызмы?

— Әйе, бүген көн җылы. Без урманга барабыз.

**4. Исеңә төшер!**

Ул бар+**а**. — Он идёт.
Ул бар+**мый**. — Он не идёт.
Ул бар+**ды**. — Он ходил.
Ул бар+**ма**+**ды**. — Он не ходил.

**5.** Тәрҗемә ит.

1) Я иду на стадион. Я не иду на стадион.
2) Я ходил на стадион. Я не ходил на стадион.
3) Я иду в магазин. Я не иду в магазин.

4) Я ходил в магазин. Я не ходил в магазин.

5) Я выхожу на улицу. Я не выхожу на улицу.

6) Я вышел на улицу. Я не вышел на улицу.

7) На улице идёт дождь. На улице дождь не идёт.

8) На улице был дождь. На улице не было дождя.

**6**. Үрнәк буенча таблицаны тутыр.

| | Хәзерге заман хикәя фигыль | | Үткән заман хикәя фигыль | |
|---|---|---|---|---|
| | барлык | юклык | барлык | юклык |
| бар<br>кит<br>кайт<br>аша | бар+а | бар+мый | бар+ды | бар+ма+ды |

**7.** Диалогны репликалар өстәп укы. Иптәшең белән сөйләш.

— ... ?

— Юк, мин урамга чыкмыйм.

— ... ?

— Чөнки көн бик салкын.

— Урамда салкын, ләкин җил юк.

— ... ?

— Әйе, урамда малайлар бар. Футбол уйныйлар. Чыгасыңмы?

— ... .

**8.** Табышмакның җавабын тап.

Кулсыз, аяксыз — тәрәзә кага (стучит).

**9.** Шигырьне укы, ошаса, ятла.

### Көз һәм балалар җыры

— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Кәрзинемдә кыярлар,
Помидор һәм алмалар.
— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Кәрзинемдә яңгырлар,
Җылы-суык көннәр бар.
— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Әбиемә, бабама
Күчтәнәчләр, бүләкләр.

Гөлсинә Гәрәева



## 42–43 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**һавá торышы́ турындá** — о погоде
**җил тóньяктан** — ветер с севера, ветер северный
**җил кóньяктан** — ветер с юга, ветер южный
**явымсы́з** — без осадков
**болытлы́** — облачно

**2.** Әйтик, син диктор. Һава торышын әйтергә өйрән.




Бүген унынчы октябрь. Көн болытлы. Кар ява. Җил төньяктан.

Төнлә Казанда температура минус 2 °C, минус 3 °C, көндез плюс 1 °C, плюс 2 °C.

**3.** Уйла һәм әйт: бу һава торышы кайсы ел фасылына туры килә?

1) Көн эссе, явымсыз, көндез температура плюс 30 °С, төнлә плюс 20 °С.

2) Көн болытлы, кар, урыны белән буран. Җил төньяктан. Температура минус 22 °С.

**4. Исеңә төшер!**

| Сораулар / Авазлар | кая? | кайда? | кайдан? |
|---|---|---|---|
| Сузыклар: калын | **-га** | **-да** | **-дан** |
| нечкә | **-гә** | **-дә** | **-дән** |
| Тартыклар: | | | |
| яңгырау | **-га, -гә** | **-да, -дә** | **-дан, -дән** |
| саңгырау | **-ка, -кә** | **-та, -тә** | **-тан, -тән** |
| [н], [м], [ң] | **-га, -гә** | **-да, -дә** | **-нан, -нән** |

**5.** Диалогны укы, дустың белән сөйләш.

— Әйдә урманга барабыз.
— Юк, мин бармыйм.
— Нигә?
— Мин һава торышын тыңладым. Яңгыр була.
— Ә син кайдан кайтасың?
— Мин стадионнан кайтам. Стадионда да яңгыр ява.
— Безнең урамда яңгыр яумый әле.

**6.** 5 нче күнегүдән фигыльләрне тап, заманнарын билгелә.

**7.** 5 нче күнегү эчтәлегенә охшаш диалоглар төзе, иптәшең белән сөйләшегез.

**8.** Допустим, ты диктор и объявляешь прогноз погоды. Как скажешь, что на улице:

— тепло, ветра нет, температура +8 °C;
— идёт дождь, сильный ветер, температура +10 °C;
— холодно, вьюга, температура –18 °C.

## 44–45 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| Мин бара́+**м.** | Без бара́+**быз.** |
| Син бара́+**сың.** | Сез бара́+**сыз.** |
| Ул бара́. | Ала́р бара́+**лар.** |

**2.** Җөмләләр төзе.

Мин — зоопарк / урман / мәктәп / китапханә ? -га / -гә / -ка / -кә — барам.

**3.** Уточни:

— идёт ли Марат в аптеку, в лес, в школу;
— идут ли друзья в аптеку, в лес, в школу.

**4.** Дару үләннәренең исемнәрен дөрес укыйсыңмы?

[ба°қа́ йа°фрағы́], [үги а°на́ йа°фрағы̆́], [қы̆чы̆тқа́н].

**5.** Текстны укы. Син нинди дару үләннәрен беләсең?

**Дару үләннәре**

Безнең урманнарда дару үләннәре күп. Дару үләннәре файдалы. Без бака яфрагы, мәтрүшкә, кычыткан җыйдык. Дару үләннәрендә витаминнар күп.

**дару үләннәре** — лекарственные травы

**6.** Тексттан дару үләннәренең исемнәрен тап, дәфтәреңә яз һәм тәрҗемә ит.

**7.** Рәсемнәргә карап, дару үләннәренең исемнәрен әйт, җөмләләр төзе.



**8.** Диалогларны укы. Сөйләшергә өйрәнегез.

а) — Оля, син кая барасың?
— Даруханәгә. Әбием авырый.
— Нинди дару аласың?
— Мин дару алмыйм, дару үләне алам.

ә) — Алсу, син нинди дару үләннәрен беләсең?
— Мәтрүшкә, кычыткан, бака яфрагы.

**9.** Какие вопросы ты задашь, чтобы получить такие ответы?

— ... ?
— Без урманда, болында булдык.
— ... ?
— Дару үләннәре җыйдык.
— ... ?
— Мәтрүшкә, ромашка җыйдык.



## 46–47 нче дәресләр

**1.** Текстны укы. Текстка исем бир.

Мин Татарстанда яшим. Татарстанның табигате бик бай. Анда урманнар, зур елгалар, матур күлләр, чиста чишмәләр күп. Урманнарда нарат, каен, имән, чыршы, нарат, юкә агачлары үсә.

Ә нинди генә җәнлекләр юк урманнарда! Анда бүре, төлке, куян, кабан дуңгызы, поши, тиеннәр яшиләр.

Мин Татарстан табигатен бик яратам.

**кабан дуңгызы** — кабан
**поши** — лось

**2.** Рәсемне яхшылап кара. Рәсемгә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укы.



**3.** Текст эчтәлегенә сораулар куй. Дустың белән сөйләш.

**4.** Җөмләләргә төшеп калган сүзләрне куеп яз.

Татарстанда урманнар, ..., ..., ... күп. Урманнарда ..., ..., ..., ..., ..., ... агачлары үсә. Урманда ..., ..., ..., ..., ..., ... яшиләр.

**5.** Хикәяне иң яхшы сөйләүчегә конкурс! Сөйләүчегә бәя бирергә онытма.

**Эчтәлекне ничек сөйли?**

Эчтәлекне дөрес сөйли.
Эчтәлекне дөрес сөйләми.

**Сүзләрне ничек әйтә?**

Сүзләрне дөрес әйтә.
Сүзләрне дөрес әйтми.

**Ничек сөйли?**

Сәнгатьле сөйли.
Сәнгатьле сөйләми.

**6. Исеңдә калдыр!**

**Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе**
Сравнительная степень прилагательных

Когда сравниваем признаки предметов, говорим так:

зур+**ра́к** — больше
ямшел+**рә́к** — зеленее
матур+**ра́к** — красивее
биек(г)+**рә́к** — выше

**7.** Составь предложения, используя рисунки и сравнительную степень прилагательных.



**8.** Сорауларга җавап бир.

1) Нәрсә матуррак: наратмы, чыршымы?
2) Нәрсә зуррак: аюмы, бүреме?

**9.** Расскажите содержание упражнения №1 друг другу.

## 48–49 нчы дәресләр

**1.** Шигырьне укы.



**Беренче кар**

Йомшак кына кар яуды.
Бөтен җирне каплады:
Ап-ак булды болыннар,
Ап-ак булды киң кырлар.

Әхмәт Ерикәй

**2. Исеңдә калдыр!**

**Сыйфатларның артыклык дәрәҗәсе**
Превосходная степень прилагательных

**бик зур** — очень большой
**иң мату́р** — самый красивый
**я́мь-яшел** — зелёный-презелёный
**а́п-ак** — белый-пребелый
**кы́п-кызыл** — красный-прекрасный

**3.** 1 нче күнегүдәге шигырьдән сыйфатларны тап, дәрәҗәсен билгелә.

**4.** Прочитай предложения. Найди прилагательные и определи, как выражены признаки предметов.

1) Бу алма кызыл. Өстәлдәге алма кызылрак. Ә агачтагы алма кып-кызыл. 2) Бу чәчәкләр зәңгәр, ә бу чәчәк зәп-зәңгәр. 3) Бу күлмәк чиста, ап-ак. 4) Синең бантигың бик матур. 5) Миңа иң зур алманы бир әле. 6) Бу алма зуррак, матуррак.

**5.** Бу җөмләләр кайсы рәсемгә туры килә?

1) Бу — иң зур помидор. 2) Бу помидор кечкенә. 3) Бу — зур помидор. 4) Бу помидор зуррак. 5) Бу помидор бик зур.



**6.** Диалогны укы, дустың белән сөйләш.

— Олег, әйдә урамга чыгабыз.
— Ә урамда рәхәтме?
— Рәхәт. Ап-ак кар ява.
— Чаңгы шуабызмы?
— Юк, зур кар бабай ясыйбыз.

**7.** Переведи.

В Татарстане есть очень большие реки: Волга, Кама, Ик, Вятка. Волга — самая красивая река, а Ик — самая длинная река в Татарстане. Вятка тоже красивая река.



## 50–51 нче дәресләр

**1.** Переведи:

Природа, земля, вода, солнце, луна, время года, дождь, река, деревья, лекарственные травы.

**2.** Дәвам ит:

1) Табигать ул — ... .
2) Елның дүрт фасылы: ...

3) Бүген көн (нинди?) ... .
4) Татарстандагы агачлар: ... .
5) Татарстандагы җәнлекләр: ... .

**3.** Сорауларга җавап бир.

Ка́йсы күбәлә́к зурра́к?





Ка́йсы кәрзиндә́ алма́ күбрә́к?

Нә́рсә тәмлерә́к?



**4** Спроси у друга, нравится ли ему зима (лето, весна, осень).

**5.** Ребусларны чиш.

••,  •••,,  ,••







•••  •••  ,•






Ш=Р



+Ы

**6.** Напиши названия рек, которые протекают по Республике Татарстан.

# ХАЙВАННАР ҺӘМ КОШЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

## 52–53 нче дәресләр

**1.** Кош исемнәрен дөрес итеп әйтергә өйрән. Тәрҗемәсен тап.

[қа°рлы̆ға́ч], [са°ндуға́ч], [күкә́], [чы̆пчы́қ], [пә̆снә́к], [күгәрчә́н], [қа°рға́], [тŏрна́], [а°қ̄о́ш], [туқра́н], [қы́р қа°зы́], [қы́р үрдәгә́].

**2.** Рәсемнәргә кара һәм кош исемнәрен татарча әйт.



**3.** Нинди кошлар бездә кала. Нинди кошлар бездән китәләр?

| Бездә кышлыйлар | Бездән китәләр |
|---|---|
| ... | ... |

Карлыгач, сандугач, күке, чыпчык, песнәк, күгәрчен, карга, торна, аккош, кыр казы, тукран, кыр үрдәге.

4. Спроси у друга:

— какие птицы зимуют у нас;
— какие птицы улетают в тёплые края.

5. Такмазаларны (прибаутки) укы. Ошаганын ятла.



Карга әйтә: «Кар, кар,
Җирдә чеби бар, бар.
Берсен генә алыр идем —
Саклаучысы бар, бар».

Тук, тук, тукран,
Тукылдатып утырам.
Агачтагы кортларның
Барсын чүпләп бетерәм.



6. «Очты, очты...» уенын искә төшер!

**Очты, очты...**



Очты, очты — каргалар очты.
Очты, очты — чыпчыклар очты.
Очты, очты — курчаклар очты.
Очты, очты — уенчыклар очты.
Очты, очты — үрдәкләр очты.
Очты, очты — казлар очты.
Очты, очты — тазлар очты.
Очты, очты — тавыклар очты.

## 54–56 нчы дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**ашый** — кушает
**ашатам** — кормлю
**ашыйсы килә** — хочется есть
**эчә** — пьёт
**эчертәм** — пою
**эчәсе килә** — хочется пить

**2. Исеңә төшер!**

| **нәрсә?** | **нәрсәне?** | **нәрсәнең?** |
|---|---|---|
| песнәк | песнәкне | песнәкнең |
| ул | аны | аның |

**3.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куй.

1) Мин Акбай... ашатам. 2) Саша кошлар... ашата. 3) Алсу песи... сөт эчертә. 4) Әнисә песнәк... май ашата. 5) Песнәк... ашыйсы килә. 6) Мин энем... ботка ашатам. 7) Энем... ботка ашыйсы килә.

**4.** Диалогларны укы. Партадашың белән сөйләшегез.

а) — Оля, нәрсә ашыйсың килә?
— Мин бәлеш яратам.
— Минем өчпочмак ашыйсым килә.
— Әйдә пешерәбез.

ә) — Энемнең ашыйсы килә.

— Әйдә ботка пешерәбез.
— Әйе, мин аңа ботка ашатам.

**5.** Нокталар урынына тиешле кушымчалар куй, дәфтәреңә яз.

Песнәк кыш көне авыл... , шәһәр... яши. Балалар песнәк... ашаталар. Песнәк... дуслары күп.

**6.** Хикәяне укы һәм уйла: Әнисә нинди кыз?

**Песнәк белән Әнисә**

Кыш көне иде. Көннәр бик салкын. Беркөнне тәрәзәгә бер песнәк кунды. Ул тәрәзәне чукый башлады.

— Әни, нигә песнәк тәрәзәне чукый? — дип сорады Әнисә.

— Тышта нинди салкын! Аның ашыйсы килгән, — диде әнисе.

— Алайса мин аны ашатам, — диде Әнисә.

Ул тәрәзәне ачты һәм бер кисәк май куйды. Песнәк бик шатланды. Канатын какты, Әнисәгә рәхмәт әйтте.



Песнәк көн саен тәрәзәгә килеп куна иде. Ул Әнисәгә ияләште һәм ачык тәрәзәдән өйгә керә башлады.

Гасыйм Лотфидан

**кунды** — подсела
**чукый башлады** — начала клевать

**канатын какты** — махнула крылом
**иялəште** — привыкла

7. Бу сүзлəрне дөрес укыйсыңмы? Аларны транскрипция билгелəре белəн яз.

Беркөнне, песнəк, чукый, тышта, шатланды, кунды, канат.

8. Найди в тексте предложения о том, что:

— на улице холодно;
— синица проголодалась;
— Аниса накормила синицу.

9. Бу раслаулар дөресме?

— Көннəр салкын түгел иде.
— Песнəк ишек янына килде.
— Песнəк тəрəзəне чукый башлады.
— Песнəкнең ашыйсы килə.
— Песнəкнең өйгə керəсе килə.
— Əнисə песнəкне ашатмады.
— Песнəк майны ашап бетерде.
— Песнəк Əнисəдəн курыкмады.
— Песнəк Əнисəгə иялəште.
— Песнəк өйгə керə башлады.

10. Хикəяне сəнгатьле укырга өйрəн.

Кошлар нəрсə ашый?

## 57–58 нче дәресләр

**1.** Җөмләләрне «Песнәк белән Әнисә» хикәясе эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1) Беркөнне тәрәзәгә песнәк кунды. 2) Кыш көне иде. 3) Песнәк тәрәзәне чукый башлады. 4) «Песнәкнең ашыйсы килгән», — диде әнисе. 5) Песнәк Әнисәгә иярләште. 6) Әнисә тәрәзәне ачты һәм бер кисәк май куйды. 7) Песнәк Әнисәгә рәхмәт әйтте.

**2.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне яз.

1) Көн..әр бик салкын. 2) Берк..нн.. тәр..зәгә п..сн..к кунды. 3) Т..р..з..н.. ч..кый б..шл..ды. 4) П..сн..кнең ашый..ы килә иде. 5) Әнис.. п..сн..к..ә май бирде. 6) П..сн..к бик ш..тл..нды. 7) П..с..әк Әнис..г.. и..ләште.

**3.** План пунктларын хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр (расположи пункты плана в последовательности содержания текста).

1) Песнәк Әнисәгә иярләшә.
2) Әнисә песнәкне ашата.
3) Песнәк Әнисәгә рәхмәт әйтә.
4) Көннәр бик салкын.
5) Әни белән кыз.

**4.** Иң яхшы хикәя сөйләүчегә конкурс! Бәя бирергә онытма!

**5.** Әгәр песнәк сөйләшә белсә, песнәк белән Әнисә арасында нинди сөйләшү булыр иде? Диалогны дәвам ит.

— Әнисә апа, исәнме!
— Исәнме, кошчыгым!
— Әнисә апа, миңа бик салкын!
— ... .

**6.** Фикерләрне дәвам ит.

Әнисә — яхшы кыз, чөнки ... .
Әнисә миңа ошый, чөнки ... .
Әнисә кошларны ярата, шуңа күрә ... .

**7.** Әгәр Әнисә яхшы күңелле кыз булмаса, кошларны яратмаса (если бы не любила птиц), хикәя ничек үзгәрер иде? Яңа хикәя язып кара.

**8.** Спроси у друга:

— помогает ли он птицам;
— сделал ли он кормушку;
— кормит ли он птиц.

**9.** Рәсемнәр урынына — күплек сандагы исемнәр, нокталар урынына кушымчалар куй, җөмләләрне дәфтәреңә яз.

Без  ... бик яратабыз. Без аларга  куябыз.  ...  сала... .

## 59–60 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укы.

Җимлек [җимлэ̆́к], тау [таºw], ясады [йаºсады̆́], агач [аºға́ч], куйды [қуйды̆́], кошлар [қŏшла́р], Вәли [wәли́], рәхмәт [рәхмә́т].

**2. Запомни!**

**җимле́к** — кормушка
**җимлеккә́** — в кормушку
**ясады́** — изготовил, сделал

**3.** Дима нәрсә ясады?

Дима







ясады́.

**4.** Димадан сора (спроси): ул нәрсә ясады?

**5.** Как скажешь о том, что ты изготовил стол, стул, кормушку?

**6.** Составь текст из данных предложений.

1) Кичә Дима җимлек ясады. 2) Җимлеккә ипи салды. 3) Ул кошларга җимлек куйды. 4) Алар Димага рәхмәт әйттеләр. 5) Кошлар ипине ашадылар.

**7.** Дима нинди малай? Ни өчен алай уйлыйсың (так думаешь)?

**8.** Диалогларны дәвам ит.

а) — Нинди матур җимлек! Кем ясады?
— ... .

ә) — Петя, син җимлек ясадыңмы?
— Әйе, мин ике җимлек ясадым.
— Аларны кая куйдың?
— ... .

б) — Саша, җимлеккә нәрсә куйдың?
— Мин җимлеккә ипи куйдым.
— Кошлар килделәрме?
— ... .

**9.** Перескажи содержание текста упражнения №6.

# 61–62 нче дәресләр

**1.** Рәсемнәрдәге хайваннар һәм кошлар кайда яши? Үрнәк буенча яз.

Үрнәк: Чуртан суда яши.












**2.** Җөмләләрдән сыйфатларны тап, дәрәҗәләрен билгелә.

1) Ак куян зур, ә соры куян зуррак. 2) Төлке усал, ә бүре усалрак. 3) Аю әкрен йөгерә, бүре тиз йөгерә, ә куян бик тиз йөгерә.

**3.** Сүзләрне тәрҗемә ит, дөрес әйтергә өйрән.

Соры, ак, кара, озын колаклы, озын койрыклы, хәйләкәр, усал, ит бирә, сөт бирә, йон бирә, тиз йөгерә, зур.

**4.** Беренче күнегүдәге хайваннар турында син нәрсәләр сөйли аласың?

**5.** Табышмакларны укы. Җавапларны рәсемгә карап әйт.

1) Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Сарыклар эзли.

2) Нечкә билле,
Көлтә койрыклы.

3) Бер йомгакка мең энә,
Сиңа тими, син тимә.

4) Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак.



**6.** Табышмаклардагы тасвирлауларны (описания) кулланып, рәсемдәге хайваннар турында сөйлә.

**7.** Спроси у друга:

— был ли он в зоопарке;
— каких животных он видел;
— видел ли он медведей;
— какое животное ему понравилось.

**8.** Предложи другу пойти в зоопарк. Убеди его, что там интересно.

**9.** «Зоопаркта» темасына кечкенә хикәя төзе.

## 63–64 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне яз.

Ак...ош, к...гәрчен, үрд...к, та...ык, т...р...зә, шатл...на, хәрәк...тч...н.

**2.** Спроси у друга:

— любит ли он птиц;
— когда улетают птицы;
— какие птицы остаются у нас, а какие улетают в тёплые края;
— кормит ли он зимой птиц;
— чем он кормит птиц зимой.

**3.** Вспомни рассказ «Песнәк белән Әнисә». Что ты можешь сказать о девочке Анисе? Какая она?

**4.** Син нинди кошларны беләсең, алар турында нәрсәләр сөйли аласың?

**5.** Заполни таблицу.

Сыер, сарык, төлке, бүре, эт, кәҗә, арыслан, юлбарыс, фил, леопард, ат, куян, дөя.

| Кыргый хайваннар | Йорт хайваннары |
|---|---|
| ... | ... |

**6.** Нокталар урынына сыйфатлар өстәп әйт.

Арыслан ... , фил ... , куян ... , бүре ... , дөя ... , аю ... , тиен ... , ташбака ... , керпе ... , төлке ... .

**7.** Ребусны чиш. Җәнлекләр турында сөйлә.

1)



2)



**8.** Җөмләләр төзе.

Бүре<br>Тиен<br>Керпе<br>Фил<br>Аю<br>Куян

?

чикләвек<br>ипи<br>сөт<br>бал<br>ит<br>кишер

ярата.

# СӘЛАМӘТЛЕК — ЗУР БАЙЛЫК

## 65–66 нчы дәресләр

**1.** Назови части тела.



**2. Исеңә төшер!**

**авырта** — болит　　　**авырыйм** — болею
**авыру** — больной
**кайсы җирең авырта?** — что болит?

**3.** Переведи:

Баш, колак, бит, бармак, чәч, борын, авыз, кул, теш, авырта, дару, сөлге, сабын, тарак, ю, юа.

**4.** Җөмләләрне укы, сораулар куй. Үзара сөйләшегез.

Минем
- күз
- колак
- борын
- баш
- аяк

авырта (авыртмый).

**5.** Скажи, что у тебя болит рука (зуб, нога, палец, ухо).



**6.** Скажи, что у тебя не болит рука (зуб, нога, палец, ухо).

**7.** Спроси у друга, болит ли у него рука (зуб, нога, палец, ухо).

**8.** Представь, что твой друг заболел. Предложи ему:






— пить чай с мёдом, молоком;
— пить лекарство.

**9.** Спроси у друга:

— что у него болит;
— был ли он у врача;
— измерил ли он температуру;
— пил ли он лекарство.



## 67 нче дәрес

**1.** Подумай и скажи, к каким (зимним или летним) видам спорта относятся эти предметы.







**2.** Рәсемдәге предметларны кулланып, диалогларны дәвам итегез, үзара сөйләшегез.

а) — Синең тимераягың бармы?
— Әйе, минем тимераягым бар.

ә) — Синең тимераягың бармы?
— Юк, тимераягым юк.

**3.** Предложи другу:

— пойти на стадион;
— поиграть в футбол;
— вместе поиграть на улице;
— вместе покататься на велосипеде.

**4.** Предложи другу поиграть в шашки (домино, шахматы).

## 68–69 нчы дәресләр

1. **Исеңдә калдыр!**

**ярыш** — соревнование
**чаңгы ярышы** — лыжные соревнования

2. Сорауларга җавап бир, җөмләләрне дәвам ит.

| **Нәрсә бара?** | **Кая барасың?** |
| --- | --- |
| Чаңгы ярышы бара. | Чаңгы ярышына барам. |
| Волейбол … … . | Волейбол … … . |
| … | … |

3. Дополни диалоги. Поговорите с соседом по парте.

а) — Коля, син чаңгы ярышына барасыңмы?
— … .
— Ә чаңгы ярышы кайда була?
— … .

ә) — Айгөл, син чаңгы ярышына бардыңмы?
— Әйе, бардым.
— … ?
— Беренче урын алдым.
— … !

4. Хикәяне укы. Син Федяга нинди киңәш бирер идең?

### Дуслар

Игорь белән Федя — дуслар. Җәй көне бергә футбол уйныйлар, кыш көне чаңгы шуалар. Алар икесе дә бик яхшы шуалар.

Менә бүген чаңгы ярышы була. Малайлар бергә чаңгы ярышына киттеләр. Тиздән финиш. Алар бергә киләләр иде. Кинәт Игорь егылды. Аның чаңгысы сынды, аягы авыртты. Ә финиш бик якын. Федяга нишләргә?




**тиздән** — скоро
**сынды** — сломалась
**якын** — близко
**егылды** — упал
**кинәт** — вдруг

**5.** Син бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

Кыш көнө [қы́ш көнө́], чаңгы [чаңғы́], шуалар [шуа́лар], ярыш [йа°ры́ш], яхшы [йа°хшы́], сынды [сынды́], авыртты [а°wырт̄ы́].

**6.** Нокталар урынына нинди хәрефләр куярсың?

…хшы …рыш й…зә
…кын …гылды й…герә

**7.** Хикәядән фигыльләрне тап. Таблицага яз.

| Действие происходит сейчас | Действие уже произошло |
| --- | --- |
| уйныйлар | уйнадылар |
| … | … |

**8.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп укы.

Җәй ... бергә ... уйныйлар, кыш ... ... шуалар. Алар икесе дә бик ... шуалар. Бүген алар ... чаңгы ... киттеләр. Кинәт Игорь ... . Финиш бик ... .

**9.** Сорауларга җавапны хикәядән тап.

1) Игорь белән Федя бергә нишлиләр? 2) Алар чаңгыда ничек шуалар? 3) Чаңгы ярышында нәрсә булды?

**10.** Хикәянең эчтәлеген (содержание) бер-берегезгә (друг другу) сөйләгез.

## 70–71 нче дәресләр

**1.** Бу җөмләләрнең эчтәлеге «Дуслар» хикәясенә туры киләме (подходит)?

1) Игорь белән Федя җәй көне бергә футбол уйныйлар, кыш көне чаңгы шуалар.
2) Игорь белән Федя бүген волейбол ярышына киттеләр.
3) Чаңгы ярышында Игорь егылды.
4) Игорьның чаңгысы сынды, аягы авыртты.
5) Финишка ерак әле.

**2.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1) Алар бергә чаңгы ярышына киттеләр. 2) Игорь белән Федя — дуслар. 3) Тиздән финиш. 4) Аның

чаңгысы сынды, аягы авыртты. 5) Кинәт Игорь егылды.

**3.** «Дуслар» хикәясен иң яхшы сөйләүчегә конкурс!

**4.** Как скажешь, что:

— завтра будут лыжные соревнования;

— Коля ушёл на лыжные соревнования?

**5.** Спроси у друга:

— любит ли он кататься на санках;

— играет ли он зимой на улице;

— с кем он больше любит играть.

**6.** Бу диалоглар кайсы рәсемгә туры килә?



а) — Игорь, тизрәк! Финиш якын!

— Федя, мин егылдым. Аягым авырта.

— Хәзер мин сиңа булышам.



ә) — Игорь, тизрәк! Финиш якын!

— Федя, мин егылдым. Аягым авырта.

— Үзең тор! Мин финишка киттем.

**7.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Федя ярдәм итмәде, чөнки ... .
2) Федя ярдәм итте, чөнки ... .
3) Федя ярдәм итте, шуңа күрә ... .

**8.** Как бы ты продолжил рассказ «Дуслар»? Напиши.

**9.** Расскажите друг другу написанный вами рассказ.

## 72–74 нче дәресләр

**2.** Текстны укы һәм сөйләп кара.



Абдулла Алиш — балаларның яраткан язучысы. Ул матур-матур хикәяләр, шигырьләр, әкиятләр язган, балалар өчен газета-журналлар да чыгарган. «Куян кызы» әкиятен дә Абдулла Алиш язган.

**2.** Сүзләрне дөрес укы, тәрҗемә ит.

Соры [сŏрŏ́], колак [қŏла́қ], итек [итэ̆́к], аяк [а°йа́қ], авырта [а°wы̆ртá], авырый [а°wы̆ры́й], яланаяк [йа°ланайа́қ], дәвалый [дәwалы́й], хайваннар [ха°йwан̄а́р].

**2.** Сүзләрнең парларын тап.

салкын — ? — куян
соры — йөри
җылы — дәвалый
доктор — көн
яланаяк — итекләр

**4.** Рәсемгә кара һәм әйт: Доктор Айболит янына нинди хайваннар килгән? Аларның кай җире авырта?



**5.** Партадашыңнан сора: хайваннарның кай җире авырта?

**6.** **Исеңә төшер!**

**Билгесез үткән заман хикәя фигыль**
**Прошедшее неопределённое время глагола**

Аффиксы **-ган/-гән, -кан/-кән** употребляем, когда речь идёт о прошедших событиях и действиях, которых мы сами не видели или о которых не очень хорошо помним:

яшәдé — яшә+**гә́н**, барды́ — бар+**га́н**,

әйттé — әйт+**кә́н**, кайтты́ — кайт+**ка́н.**

Эта форма глагола часто встречается в текстах сказок.

**7.** Үрнәк буенча үзгәрт.

Үрнәк: чыкты — чыккан.
Авыртты, туңды, йөрде, йөгерде, уйнады, сөртте.

**8.** Тәрҗемә ит.

1) Әнисе кызга җылы итекләр алып кайткан. 2) Кызга итекләр бик ошаган. 3) Ул урамга чыккан, ләкин итекләрне кимәгән. 4) Ул карда да, бозда да яланаяк йөгергән. 5) Кыз бик авырган. 6) Доктор Айболит кызга дарулар биргән.

**9.** Әкиятне укы.

## Куян кызы

Бер соры Куянның бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик яраткан. Бервакыт Куян кызына яңа киез итекләр алып кайткан.

— Мә, кызым, аякларың туңмасын, авыртмасын, — дигән.

Кыз бик шатланган. Әнисенә рәхмәт әйткән. Яңа киез итекләрне кигән, бик озак уйнаган.

Ләкин Куян кызы җылы итекләрдән бик тиз туйган һәм салып куйган. Карда да, бозда да яланаяк йөгергән. Бер көн



шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөгергән. Бервакыт әнисе янына килгән.

— Әни, әни, минем аягым бик авырта! — дигән.

— Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аякларың туңган бит, — дип кайгырган әни Куян.

Шул вакыт агач башында йөргән Тиен болай дигән:

— Кайгырма, йомшак Куянкай. Син Доктор Айболитка бар, киңәш сора.

Доктор Айболит Куян кызына дарулар биргән һәм аңа әйткән:

— Киез итекләрне салма, әниеңне тыңла, — дигән.

Доктор Айболитка алар бик зур рәхмәт әйткәннәр. Өч көндә Куян кызының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмый, ди.

Абдулла Алиштан

**киез итек** — валенки
**туңмасын** — пусть не замёрзнут
**туйган** — надоело
**кигән** — надел
**яланаяк** — босиком
**салма** — не снимай
**төзәлгән** — вылечилась

Тыңла һәм укы!

**10.** Җөмләләрне әкият эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1) Куян кызы итекләрне кимәгән. 2) Әни Куян кызына яңа киез итекләр сатып алган. 3) Әни, минем аягым бик авырта! 4) Өч көндә Куян кызының аягы төзәлгән. 5) Алар Доктор Айболитның өенә килгәннәр. 6) Доктор Айболитка бар, киңәш сора.

**11.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1) Әнисе кызга яңа тун алып кайткан.
Әнисе кызга яңа киез итекләр алып кайткан.

2) Куян кызы киез итекләрне салып ташлаган.
Куян кызы итекләрне беркайчан да салмаган.

3) Әни, минем аякларым авырта!
Кызым, минем аякларым авырта!

**12.** Рәсемнәргә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укы.









**12.** Диалогларны текст эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

а) — Кайгырма, йомшак Куянкай. Син Доктор Айболитка бар. Ул ярдәм итә.
— Рәхмәт, Тиен дус.

ә) — Кызым, мә итекләр. Аякларың туңмасын, авыртмасын.
— Рәхмәт, әнием. Нинди матур, нинди җылы итекләр!

б) — Доктор Айболит, ярдәм итегез, кызымның аяклары авырта.
— Менә дарулар. Ә син, Куян кызы, салкын көннәрдә итекләрне салма, әниеңне тыңла.

в) — Әни, минем аягым бик авырта!
— Кызым, синең аякларың туңган бит.

**13.** Әкиятне сәнгатьле укырга өйрән.

## 75–77 нче дәресләр

**1.** Абдулла Алишның «Куян кызы» әкиятен сәхнәләштерегез. Иң яхшы уйнаучыларны билгеләгез.

**2.** Сорауларга җавап бир.

1) Әнисе Куян кызына нәрсә алып кайткан?
2) Куян кызының аяклары нигә авырткан?

3) Куян кызы әнисе белән кая барган?
4) Доктор Айболит нәрсә әйткән?

**3.** Сораулар буенча әкиятнең эчтәлеген сөйлә.

**4.** Ничек уйлыйсың, Куян кызына бу сыйфатларның кайсы туры килә?

Иркә, ялкау, тәртипсез, җитез, шаян, әнисен тыңлый, әнисен тыңламый.

**5.** **Исеңдә калдыр!**

**Инфинитив**

Инфинитив отвечает на вопрос **ни́шләргә?** (что делать? что сделать?) и образуется: в положительной форме присоединением к основе на гласный звук аффиксов **-рга/-ргә**, к основе на согласный звук аффиксов — **-ырга/-ергә, -арга/-әргә.**

Инфинитив в речи часто употребляется со словами: **кирә́к** — надо; **кирә́кми** — не надо; **яры́й** — ладно, можно; **яра́мый** — нельзя, невозможно; **мөмки́н** — можно; **тие́ш** — должен; **тие́ш түге́л** — не должен.

**6.** Вместо точек вставьте нужные окончания.

1) Әни, урамга чы(к)... ярыймы? 2) Мин чаңгы шу... яратам. 3) Кызым, урамда салкын, киез итекләрне ки... кирәк. 4) Мин киез итекләр ки... яратмыйм. 5) Кызым, докторга бар... кирәк. 6) Син бу даруларны эч... тиеш.

**7.** Посоветуй другу:

— всегда слушаться маму;
— в холодные дни тепло одеваться;
— пойти к доктору.

## 78–79 нчы дәресләр

**1.** Рәсемгә кара һәм әйт. Бу җөмләләрнең кайсы рәсемгә туры килә?

1) Бер кыз көлә. 2) Мин шугалакта егылдым. 3) Мин тимераяк кидем. 4) Минем аягым авыртты. 5) Мин бозга егылдым.



**2. Исеңдә калдыр!**

**шуа́ белә́** — умеет кататься
**шуа́ бе́лми** — не умеет кататься
**егылды́** — упал

**3.** Диалогны укы. Үзара сөйләшегез.

— Олег, нәрсә булды?
— Мин егылдым.
— Кайсы җирең авырта?
— Минем аягым авырта.

**4.** Җөмләләрне файдаланып (используя), рәсем буенча хикәя төзе.

1) Малай тимераякта шуа белми. 2) Ул егыла. 3) Ул бозга башы белән егыла. 4) Малайны бер кыз күрә. 5) Кыз малайдан көлә.

**5.** Как скажешь о том, что:

— ты не умеешь кататься на коньках;
— ты умеешь кататься на лыжах;
— ты не любишь кататься на коньках;
— ты любишь кататься на лыжах?

**6. Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| **ә** — а | **я** — или |
| **әйе́** — да | **түге́л** — не |
| **юк** — нет | **әлбә́ттә** — конечно |

**7.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстә.

а) — Исәнме, Илдар!
— ... .
— Син шугалакка барасыңмы?
— Барам. Ә син?
— Баштa дәрес әзерлим. Син дәрес әзерләдеңме?

— … .
— Син тимераякта шуарга яратасыңмы?
— … .
— Кайда очрашабыз?
— … .

ә) — … ?
— Юк, салкын түгел.
— … ?
— Җил көчле түгел.
— … ?
— Әлбәттә, чыгабыз.
— … ?
— Әйе, чаңгы белән чыгабыз.
— … ?
— Я тауга, я урманга барабыз.

**8.** Рәсемнәр урынына — сүзләр, нокталар урынына кушымчалар куй. Текстны укы.

Бүген ял көне. Көн җылы. Әз генә  ява. Без  … киттек. Анда балалар күп иде. Алар  ,  шуалар. Без  ясадык.  … бик озак уйнадык. Бик рәхәт булды.

**9.** 8 нче күнегү текстын бер-берегезгә сөйләгез.

## 80 нче дәрес

### Проверь себя!

**1.** Назови части тела.

**2.** Переведи:

1) Я болею, ты болеешь, он болеет.

2) Я не болею, ты не болеешь, он не болеет.

3) Болит. Болит рука. У меня болит рука. Болит ли у тебя рука?

**3.** Скажи о том, что у тебя болит рука (зуб, нога, палец, ухо).

**4.** Спроси у друга, болит ли у него рука (зуб, нога, палец, ухо).

**5.** Спроси у друга:

— нет ли у него температуры;
— выпил ли он лекарство.

**6.** Как скажешь о том, что ты:

— не выходишь на улицу, потому что болеешь;
— не идёшь на праздник;
— не идёшь на горку?

**7.** Позови друга:

— вместе поиграть на улице;
— покататься на лыжах;
— покататься на санках;
— поиграть в хоккей;
— вместе пойти на праздник.





# МИНЕМ ДУСЛАРЫМ

## 81–83 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен тап.

**дус**

**дустым**

**дуслаштык**

**бергә**

мой друг,
моя подруга

друг,
подруга

подружились

вместе

**2.** Төрләнешне дәвам ит.

Минем дустым, партадашым.
Синең … , … .
Аның … , … .

**3.** Диалогны укы һәм партадашың белән сөйләш.

— Айрат, Петя белән Шамил дуслармы?

— Әлбәттә, дуслар. Алар гел бергә футбол уйныйлар.

— Алсу, Оля белән Наилә дуслармы?

— Әлбәттә, дуслар. Алар гел бергә бию түгәрәгенә йөриләр.

**4.** Синең дустың бармы? Дустың турында сөйләргә өйрән. Сиңа таблица ярдәм итәр.

| Сөйләү планы | Терәк сүзләр, сүзтезмәләр |
| --- | --- |
| Без кайда дуслаштык? | авылда, шәһәрдә, ишегалдында, түгәрәктә, лагерьда, мәктәптә |
| Без кайчан дуслаштык? | җәй көне, кышкы каникулда, көз көне |
| Дустым кайда яши? | ... шәһәрдә, ... авылда |
| Дустым кайда укый? | ... мәктәптә, ... сыйныфта |
| Ул нинди? | күзе: зәңгәр, соры, кара<br>чәче: озын, кыска, сары, кара<br>характеры: ярдәмчел, тырыш, тәрбияле |
| Ул нишләргә ярата? | җырларга, биергә, шахмат (шашка) уйнарга, китап укырга |

**5.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстә, дустың белән сөйләш.

а) — ... ?
— Әйе, минем дустым бар.
— Аның исеме ничек?
— ... .
— ... ?
— Ул дүртенче сыйныфта укый.

ә) — Әйт әле, Надя, син Оля белән дусмы?

— Әйе, без бик дус.

— ... ?

— Авылда.

— Кайчан дуслаштыгыз?

— ... .



**6.** Диалогны партадашың белән сөйләшегез.

— Дима, синең ничә дустың бар?

— Өч.

— Аларның исемнәре ничек?

— Марат, Петя һәм Динар.

— Алар синең белән бер сыйныфта укыймы?

— Марат һәм Петя — минем сыйныфташларым. Ә Динар башка мәктәптә укый.

— Дусларың белән нишлисең?

— Без футбол уйныйбыз, бергәләп дәрес әзерлибез.

— Алар сиңа булышамы?

— Әйе, Динар миңа мәсьәлә чишәргә өйрәтә.



## 84–86 нчы дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

> **-чы/-че** кушымчалары яңа сүзләр ясый:
> бакча+**чы** — садовод
> нефть+**че** — нефтяник
> Если хочешь сказать о профессии своих родителей, то говори так:
> Минем әтием — төзүче.
> Минем әнием — укытучы.

**2.** Бирелгән сүзләрдән һөнәр исемнәре яса.

Балык, тимер, эш, китапханә, укыту.

**3.** Сүзләрне дөрес укырга өйрән.

дәрес [дәрә́с], дуслары [дуслары́], тыңлагыз [ты́ңлағы̆з], сыйныфташлар [сы̆йны̆фташла́р], табышмак [таᵒбы̆шма́қ], ямьле [йәмлә́], күңелле [күңэл̄ә́].

**4.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: кем нишли?



**5.** Хикәяне укы. Балаларга нигә күңелле булды?

### Алма

Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. Ул бик матур һәм хуш исле иде. Чулпанның алманы ашыйсы килде. Дәрес әзерләгәндә, Чулпан гел алмага карап утырды. Менә ул түзмәде, дуслары янына мәктәпкә китте.



— Дусларым, тыңлагыз әле! — диде Чулпан. — Хәзер мин сезгә бер табышмак әйтәм:

Түм-түгәрәк, тупмы әллә,
Бакчаларда юкмы әллә?
Балдан татлыдыр тәме.
Бу нәрсә?

— Алма! — дип кычкырдылар укучылар.

Балалар алманы бергә ашадылар. Аларга бик күңелле булды.

Идрис Туктардан

**хуш исле** — ароматный
**дәрес әзерләгәндә** — когда готовила уроки
**түм-түгәрәк** — круглый-круглый
**түзмәде** — не выдержала

**6.** Найди в тексте предложения о том, что:

— яблоко было красивым и ароматным;
— Чулпан пошла к одноклассникам;
— дети отгадали загадку;
— ребятам было хорошо.

**7.** Бу җөмләләр хикәя эчтәлегенә туры киләме?

1) Алма кызыл, ләкин хуш исле түгел иде.
2) Чулпанның алманы ашыйсы килде, ләкин ашамады.
3) Дәрес әзерләгәндә, Чулпан алманы ашады.
4) Чулпан дусларына алма алып барды.
5) Табышмак Чулпанның дусларына ошады.
6) Балалар табышмакның җавабын белмәделәр.
7) Балаларга бик күңелле, бик рәхәт булды.

**8.** Җөмләләрне укы. Сораулар куй.

Бабай алма бирде.
Бабай бер алма бирде.
Бабай Чулпанга бер алма бирде.
Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде.

**9.** 8 нче күнегү үрнәгендә (по образцу) җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз.

Җөмләләр: Чулпан утырды. Чулпан китте.

**10.** Сиңа «Алма» хикәясенең кайсы өлеше ошады? Иң ошаган өлешен укы.

**11.** Ничек уйлыйсың, Чулпан сыйныфташлары белән дусмы? Дуслык нәрсәдә күренә? Чулпанга нинди бәя бирер идең, дәфтәреңә яз.

**12.** «Минем чын (настоящий) дустым» дигән темага кечкенә хикәя яз.

# БЕЗНЕҢ ШӨГЫЛЬЛӘР

## 87–88 нче дәресләр

**1.** Рәсемгә кара һәм әйт, нинди шөгыльләр (увлечения) бар? Рәсемнәр буенча җөмләләр төзе.



**2.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

а) — Саша, сиңа робототехника ошыймы?
— Әйе, ошый.
— Син түгәрәккә ничә ел йөрисең?
— Ике ел.
— Сез нишлисез?
— Без төрле роботлар ясарга өйрәнәбез.

ә) — Костя, әйдә шахмат уйныйбыз.
— Мин бит уйный белмим.

— Ә мин шахмат уйнарга бик яратам. Мин сиңа булышам.

— Син ничек өйрәндең?

— Без әти белән бергә уйныйбыз.

б) — Оля, син ничек санны тиз кушасың, аласың?

— Мин бит менталь санауга йөрим.

— Сиңа ошыймы?

— Әйе, бик файдалы.

**3.** Сиңа нинди шөгыльләр ошый? Дустың белән сөйләш.

**4.** Спроси у друга:

— есть ли у него друзья;
— с кем он будет играть вечером;
— идёт ли он сегодня на стадион;
— выйдет ли он вечером.

**5.** Диалогларны укы. Дустың белән сөйләшегез.

а) — Алло, хәерле көн!

— Хәерле көн!

— Наташа, әйдә бассейнга барабыз.

— Юк әле, Лена, бармыйм.

— Нигә?

— Безнең иртәгә контроль эш. Мин дәрес әзерлим.



ә) — Алло, хәерле көн! Мин — Лена. Айгөл кирәк иде.

— Хәзер чакырам!

— Айгөл, исәнме! Син математикадан өй эшен эшләдеңме?

— Юк әле, Лена, эшләмәдем.

— Әйдә бергә эшлибез.

— Ярый, кил, мин сине көтәм.



б) — Сергей, бүген безгә кил әле.

— Нигә, Дамир?

— Минем яңа уеным бар.

— Кызык. Нинди уен?

— Әти миңа «лего» алды.

— Шәп! Мин хәзер киләм.

**6.** 5 нче күнегү эчтәлегенә охшаш диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

## 89–91 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең антоним парларын тап, җөмләләр төзе.

| | | |
|---|---|---|
| эшчән | | куркак |
| яхшы | ? | ялкау |
| батыр | | саран |
| юмарт | | начар |

**2.** Хикәяне укы.

### Минем дустым

Минем исемем — Айсылу. Мин сезгә дустым турында сөйлим. Аның исеме — Айгөл. Без аның

белән авылда җәйге каникулда дуслаштык. Айгөл дә, мин дә Казанда яшибез, бер йортта торабыз, бер мәктәптә укыйбыз. Мин — дүртенче, ә ул бишенче сыйныфта укый. Айгөл җырларга, биергә ярата.

Без бик дуслар. Без бергә биюгә йөрибез. Татар, рус, молдаван биюләре дә, заманча биюләр дә өйрәнәбез.

Дәрестән соң без бергә паркта ял итәбез, бергә дәрес әзерлибез.

Айгөл — яхшы укучы, «4»ле, «5»ле билгеләре ала. Ул бик юмарт, ярдәмчел, эшчән кыз. Өйдә ашарга пешерә, өй җыештыра.

**бер өйдә** — в одном доме
**заманча** — современный
**ярдәмчел** — отзывчивая
**эшчән** — трудолюбивая

**3.** Хикәядән сорауларга җавап тап.

1) Кызлар кайда дуслашты?
2) Кызлар кайда яшиләр?
3) Кызлар бергә нишлиләр?

**4.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1) Без Айгөл белән шәһәрдә дуслаштык.
Без Айгөл белән авылда дуслаштык.

2) Мин җәйге каникулда авылга кайттым.
Без Айгөл белән җәйге каникулда лагерьда ял иттек.

3) Без заманча биюләр өйрәнәбез.
Без заманча биюләр өйрәнмибез.

4) Айгөл — биюче, ләкин ул яхшы укымый.
Айгөл — яхшы укучы да, оста биюче дә.

**5.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп яз.

1) Мин... исем... — Айсылу. 2) Мин сез... дуст... Айгөл турында сөйләргә телим. 3) Ул — дүрт... сыйныф... , мин биш... сыйныф... укыйм. 4) Без бию түгәрәге... йөрибез.

**6.** Хикәяне сәнгатьле укучыга конкурс! Бәя бирергә (оценить) онытма (не забудь).

| | |
|---|---|
| Яхшы укый. | Яхшы укымый. |
| Дөрес укый. | Дөрес укымый. |
| Сәнгатьле укый. | Сәнгатьле укымый. |

**7.** Диалогларга төшеп калган репликаларны куй, партадашың белән сөйләш.

а) — ... ?
— Әйе, минем дустым бар.
— ... ?
— Ул шәһәрдә яши.
— Сез бергә нишлисез?
— ... .

ә) — Оля, әйдә түгәрәккә языйлабыз.
— Нинди түгәрәккә?
— ... .
— Син биергә яратасыңмы?
— ... .
— Син нишләргә яратасың?
— ... .
— Рәсем түгәрәгенә языласыңмы?
— ... .

**8.** Иң матур хикәя сөйләүчегә конкурс! Сөйләүчегә бәя бирергә онытма.

| | |
|---|---|
| Дөрес сөйли. | Дөрес сөйләми. |
| Эчтәлекне (содержание) белә. | Эчтәлекне белми. |
| Сүзләрне дөрес әйтә. | Сүзләрне дөрес әйтми. |

**9.** Диалогны укы. Үзара сөйләшегез.

— Алло, хәерле кич!
— Хәерле кич!
— Айдар, иртәгә (завтра) стадионга барасыңмы?
— Әйе, барам, Руслан, без ярышка әзерләнәбез. Ә син киләсеңме?
— Әйе. Мин Петя һәм Олег белән киләм.
— Футбол тубы алып кил әле.
— Яхшы.
— Рәхмәт.

# МИНЕМ БЕР КӨНЕМ

## 92–93 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер.**

**Сәгать ничә?** — Который час?
**Сәгать ничәдә?** — Во сколько часов?
**сәгать алты** — шесть часов
**сәгать алтыда** — в шесть часов
**сәгать алтынчы яртыда** — в половине шестого




**2.** Син бу сүзләрне хәтерлисеңме (помнишь ли)? Аларны тәрҗемә ит, дәфтәреңдә яз, җөмләләр төзе.

Утром встаёт, убирает постель, делает зарядку, умывается, завтракает, уходит в школу.

**3.** Текстны укы. Алёшаның көндәлек режимын сөйләргә өйрән.

Алёша иртән сәгать җидедә тора. Ул зарядка ясый, салкын су белән юына. Сәгать сигезенче яртыда иртәнге ашны ашый, аннан соң мәктәпкә китә.

Сәгать сигездә мәктәптә дәресләр башлана, сәгать бердә бетә. Дәресләрдән соң Алёша өйгә кайта, көндезге ашны ашый. Өйдә әнисенә булыша: кибеткә бара, өй җыештыра.

Сәгать биштә ул дәрес әзерли башлый. Ә кич саф һавада уйный.

Кич сәгать җидедә бөтен гаилә белән кичке ашны ашыйлар. Алёша сәгать унда йокларга ята.

**аннан соң** — потом
**дәрестән соң** — после уроков

**4.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: Алёша бу эшләрне кайчан эшли?



**5.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1) Сәгать сигездә мәктәптә дәресләр башлана. 2) Сәгать бердә мәктәптә дәресләр бетә. 3) Алёша сәгать җидедә тора. 4) Сәгать биштә Алёша дәрес әзерли башлый. 5) Сәгать унда ул йокларга ята.

**6.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1) Алёша сәгать җидедә тора.
   Алёша сәгать җиденче яртыда тора.

2) Алёша салкын су белән юына.
   Алёша җылы су белән юына.

3) Дәресләр сәгать тугызда башлана.
   Дәресләр сәгать сигездә башлана.

4) Дәресләр сәгать икедә бетә.
   Дәресләр сәгать бердә бетә.

5) Алёша әнисенә булышмый.
   Алёша әнисенә булыша.

6) Гаиләдә кичке ашны бергә ашыйлар.
   Алёша кичке ашны үзе генә ашый.

7) Алёша кичке унбердә йокларга ята.
   Алёша кичке унда йокларга ята.

**7.** Сәгатьләргә кара һәм Алёша турында сөйлә.









**8.** Ничек уйлыйсың, кайсы сыйфатлар Алёшага туры килә?

Житез, ялкау, тәртипсез, эшчән, тәртипле, тәрбияле.

**9.** Үзеңнең көндәлек режимың турында кечкенә хикәя төзе.

**10.** Спроси у друга:

— во сколько часов он встаёт утром;
— делает ли он зарядку;
— во сколько часов начинаются уроки в школе;
— во сколько часов кончаются уроки в школе;
— во сколько часов он ложится спать.

**11.** Схема буенча диалог төзе. Тема: «Көндәлек режим».

1) Сорау — сорау — җавап.
2) Сорау — җавап — сорау — җавап.

**12.** 10 нчы күнегүне язмача эшлә.

## 94–95 нче дәресләр

1. Диалогны укы. Дустың белән сөйләш.

— Марат, син кайчан йокыдан торасың?
— Сәгать җидедә. Ә син?
— Мин дә җидедә торам.
— Иртән син нишлисең?
— Юынам, зарядка ясыйм, чәй эчәм. Аннан соң (потом) мәктәпкә китәм.
— Син ничәнче сменада укыйсың?
— Беренче сменада укыйм. Ә син?
— Мин дә беренче сменада.
— Мәктәптән сәгать ничәдә кайтасың?
— Сәгать бердә.
— Сәгать ничәдә дәрес әзерлисең?
— Сәгать дүрттә.

2. Расскажите друг другу о своём режиме дня.

3. Прочитай и перескажи текст о Мусе Джалиле.

Муса Җәлил — күренекле татар шагыйре. Дошманга каршы көрәштә күрсәткән батырлыклары өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Муса Җәлил балалар өчен бик күп шигырьләр яза: «Әтәч», «Куян», «Маэмай», «Кечкенә дусларга».



Муса Җәлил турында укы

**4.** Сорауларга җавап бир.

1) Муса Җәлил турында нәрсәләр беләсең?
2) Аның нинди шигырьләрен укыганың бар?

**5.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

Сәгать [сәға́т], даң-даң [даºң даºң], таң [таºң], калган [каºлға́н], Марат [маºра́т], харап [хаºра́п], соңга калган [сŏңға́ қаºлға́н], карап йөр [қаºра́п йөр].

**6.** Шигырьне укы.

**Сәгать**



Сәгать суга: «Даң-даң!..»
Хәбәр итә таңнан:
Мәктәпкә барырга
Унбиш минут калган.
Сәгать йөри: «Келт-келт!..
Тиз мәктәпкә кит, кит!..»
Марат аңа дәшә:
«Тукта, мине көт, көт!»
Сәгать җырлый: «Диң-диң!..
Мин бит туктый белмим.
Моннан ары, диң, диң!
Миңа карап йөр син!..»

Муса Җәлил

**7.** Найди в стихотворении предложения, в которых говорится:

— о том, что Марат опоздал;
— о чём просит Марат у часов;
— о чём поют часы.

**8.** Выучи 4 понравившиеся строки стихотворения.

# 96–98 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең дөрес тәрҗемәсен тап.

| | | |
|---|---|---|
| алдында | | около |
| артында | | впереди |
| янында | ? | сзади |
| каршында | | перед |
| өстендә | | под |
| астында | | над |

**2.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: туп кайда?



**3.** Составь предложения, используя вопросительные частицы **-мы/-ме** и слова из упражнения №1.

**4.** Используя слова, составь по образцу предложения и переведи.

Образец: шапка — бүрек.
Нет шапки. — Бүрек юк.
Где шапка? — Бүрек кайда?
Нашла шапку. — Бүрекне таптым.
Дай шапку. — Бүрекне бир.

Слова: бияләй, тимераяк, чана.

**5.** Переведи слова, научись их правильно произносить. Они помогут тебе понять рассказ.

Тимераяк, уянды, эзләделәр, бүрек, бияләй, чыкты, боз, эрегән.

**6.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстә.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Урам... | чыкты. | Өй... | кайтты, керде. |
| Урам... | уйный. | Өй... | тора. |
| Урам... | керде. | Өй... | чыкты, китте. |

**7.** Антоним парларны билгелә.

| | | |
|---|---|---|
| озак | ? | җиңел |
| авыр | | тиз |
| алдында | | югалтты |
| тапты | | артында |
| каткан | | эрегән |

**8.** Хикәяне укы.



**Авыраяк**

Авыраяк озак йоклады. Менә ул уянды, урамга карады. Урамда боз каткан иде.

Авыраяк:

— Әни, тимераяклар кайда икән? — диде.

Әнисе тимераякларны тапты.

— Әни, минем тимераякларны бәйлә әле.

Әнисе тимераякларны бәйләде.

— Әни, минем пальто кайда?

Пальтоны бик озак эзләделәр. Ул ишек артында иде.

— Әни, әни, минем бүрегем кайда?

Авыраякның бүреге өстәл янында иде.

— Әни, әни, минем бияләйләрем кайда?

Бер бияләй карават астында, икенчесе диван астында иде.

Авыраяк урамга чыкты, ә анда инде боз эрегән иде.

Идрис Туктар

**эрегән иде** — расстаял

**9.** Ничек уйлыйсың, бу сыйфатларның кайсы Авыраякка туры килә?

Җитез, әкрен эшли, эшчән, ялкау, әйберләрне урынына куймый, тәртипле, тәртипсез.

**10.** Как ты думаешь, подходит ли мальчику его имя **Авыраяк**? Почему так думаешь?

**11.** Вспомни Марата из стихотворения «Сәгать». Чем похожи Марат и Авыраяк? Напиши в тетрадь.

## 99–100 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**җәйге́ ял** — летний отдых
**сәяхә́т** — путешествие
**сәяхә́т итәргә́** — путешествовать
**җәя́ү** — пешком
**тарихи́ уры́н** — историческое место

**2.** Диалогларны үзара сөйләшегез.



а) — Оля, син сәяхәт итәргә яратасыңмы?

— Әлбәттә. Без әтием, әнием белән сәяхәт итәбез.

— Сез кайда булдыгыз?

— Без Мәскәүдә, Санкт-Петербургта булдык.

— Санкт-Петербургта Эрмитажга бардыгызмы?

— Әлбәттә, Эрмитажда да булдык, Петергофка да бардык.

— Ә Казанга бардыгызмы?

— Әйе, каникулда Казанга бардык.



ә) — Костя, без велосипедта сәяхәткә чыгабыз.

— Кемнәр белән?

— Дуслар белән.

— Кая барасыз?
— Урманга.

б) — Без җәй көне Болгарга барабыз.
— Ә ул нинди шәһәр?
— Ул борынгы, тарихи шәһәр.
— Ә нәрсә белән барасыз?
— Казаннан Болгарга теплоходта барабыз.
— Кемнәр белән барасыз?
— Абый һәм апа белән барабыз.



в) — Аня, быел җәйге ялда бик күңелле булды.
— Ни өчен? Кая бардыгыз?
— Теплоходта сәяхәт иттек.

г) — Коля, без каникулда Казанга барабыз.
— Без дә каникулда Казанга барабыз. Сез кем белән барасыз?
— Без сыйныф белән, укытучы белән бергә барабыз, Казанда музейлар карыйбыз.
— Сез Казан Кремленә барасызмы?

— Әйе, Кол Шәриф мәчетен, Благовещение соборын карыйбыз.

д) — Сез кайда булдыгыз?

— Без Казанда «Ривьера» аквапаркында булдык.

— Анда нәрсә ошады?

— Бассейн, төрле аттракционнар ошады.



**3.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәп, үзара сөйләшегез.

— Оля, мин җәй көне теплоходта сәяхәт иттем. Ә син?

— Ә мин җәй көне диңгезгә бардым.

— Нинди диңгезгә?

— ... .

— Ничек ял иттегез?

— ... .

**4.** Узнай у друга:

— любит ли он путешествовать;

— любит ли он путешествовать на теплоходе;

— любит ли он смотреть исторические места.



**5.** Как скажешь о том, что вы:

— любите путешествовать;

— были в Москве, в Санкт-Петербурге;

— путешествовали на теплоходе по Волге?

**6.** Пригласи друга на путешествие по «Золотому кольцу» России.

## 101–102 нче дәресләр

**1.** Шигырьне сәнгатьле укы.

### Минем дуслар

Мин «Якты күл»дә
Булдым лагерьда,
Су буенда ул,
Бик матур җирдә.

Күбәйде тагын
Анда дусларым,
Алдым барысының
Мин адресларын:

Алты Рафаэль,
Унике Равил,
Уналты Ваня,
Унҗиде Шамил,

Нәсимә, Сима,
Сания, Соня,
Володя, Нина,
Верочка, Лена...

Кайткач, аларга
Яздым мин хатлар,
Истәлекләрне
Хәтердә саклап.

Баргач хатларым,
Алар шатланыр,
Һәммәсе миңа
Хат язып салыр:

Нәсимә, Сима,
Сания, Соня,
Володя, Нина,
Верочка, Лена...

Алты Рафаэль,
Унике Равил,
Уналты Ваня,
Унҗиде Шамил.

Бари Рәхмәт

**күбәйде** — стало больше
**истәлекләр** — воспоминания
**хәтер** — память



**2.** Сорауларга җавап бир.

1) Шигырьдәге герой кайда ял иткән?
2) Ул кемнәр белән дуслашкан?
3) Аның ничә дусты бар?
4) Ул кемнән хат көтә?

**3.** По данным вопросам расскажи о своём друге.

1) Синең дустың бармы?
2) Аның исеме ничек? Аңа ничә яшь?
3) Ул нинди?
4) Дустың кайда яши?
5) Ул кайда укый? Ничек укый?
6) Сез бергә нишлисез?

**4.** Узнай у друга:

— есть ли у него велосипед, мяч, гироскутер;
— идёт ли он сегодня играть в футбол;
— ходит ли он на стадион;
— играет ли он в шахматы;
— катается ли на велосипеде.





**5.** Пригласи друга:

— покататься на велосипедах (роликах, гироскутере);
— в кинотеатр;
— в поход.

**6.** Как скажешь, что:

— твой друг живёт в городе (в деревне);
— он учится в четвёртом классе;
— он учится хорошо;
— вы вместе играете?

**7.** Как скажешь о том, что ты летом:

— загораешь, купаешься;
— ходишь в лес, собираешь ягоды, грибы;
— едешь с родителями на дачу;
— помогаешь родителям на даче?

**8.** Расскажи, где ты отдыхал летом.



# Сүзлек

## А

**абый** — старший брат, дядя
**аваз** — звук
**авыз** — рот
**авыл** — деревня
**авыр** — трудно; трудный; тяжело; тяжёлый
**авырта** — болит
**авырый** — болеет
**ага** — течёт
**агач** — дерево
**агулы** — ядовитый
**аз** — мало
**азык** — пища, корм
**ай** — месяц
**ак** — белый
**акбур** — мел
**акрын** — медленно; медленный
**акула** — акула
**акча** — деньги
**акыллы** — умный
**ала** — берёт
**алан** — поляна
**алар** — они
**аларга** — им
**аларны** — их
**аларның** — у них
**алдында** — впереди
**алма** — яблоко
**алмагач** — яблоня
**алтау** — шестеро
**алтын** — золото; золотой
**алырга** — вычитать
**алъяпкыч** — фартук
**ана** — мать
**анда** — там
**аннан соң** — потом
**аны** — его, её
**аның** — его, её; у него, у неё

**аңа** — ему, ей;
к нему, к ней
**апа** — старшая сестра,
тётя
**аркылы** — через
**артта** — позади, сзади
**арыслан** — лев
**ас** — низ
**ат** — лошадь
**ата** — отец
**атна** — неделя
**ача** — открывает
**аш** — суп
**аша** — ешь, кушай
**аша** — через
**ашамлык** — продукт
**ашата** — кормит
**аш-су** — кушанье
**ашханә** — столовая
**ашый** — ест
**аю** — медведь
**аяз** — безоблачный
**аяк** — нога

## Ә

**әбәкле уйный** — играет
в догонялки
**әби** — бабушка
**әдәпле** — вежливый
**әзерли** — готовит
**әйбәт** — хорошо;
хороший
**әйбер** — вещь
**әйе** — да
**әйтә** — говорит
**әкият** — сказка
**әкрен** — медленно;
медленный
**әле** — только, ещё
**әле** — -ка (скажи-ка)
**әнә** — вот
**әни** — мама
**әрем** — полынь
**әтәч** — петух
**әти** — папа
**әфлисун** — апельсин

# Б

**бабай** — дедушка
**базар** — рынок
**бай** — богач; богатый
**бака** — лягушка
**бакча** — сад
**бакчачы** — садовник
**бал** — мёд
**бала** — ребёнок
**балан** — калина
**баллы** — сладкий
**балта** — топор
**балык** — рыба
**балыкчы** — рыбак
**бар I** — есть
**бар II** — иди
**бара** — идёт
**бармак** — палец
**барыбер** — всё равно
**баса** — встаёт
**басма** — мостик
**батыр** — герой, богатырь
**бау** — верёвка
**башкала** — столица
**башлана** — начинается
**башта** — сначала, сперва
**бәби** — младенец
**бәбкә** — гусёнок; утёнок
**бәйрәм** — праздник
**бәләкәй** — маленький
**бәлеш** — бэлиш
**бәрәңге** — картофель
**бәхет** — счастье
**бәя** — цена
**без** — мы
**безгә** — нам, к нам
**безне** — нас
**безнең** — наш
**белән** — с
**белем** — знание
**бер** — один
**бераз** — немного
**бервакыт** — однажды
**бергә** — вместе, совместно

**беренче** — первый
**беркайчан** — никогда
**беркем** — никто
**бернинди** — никакой
**берсе** — один из них
**бетә** — заканчивается, завершается
**бетергеч** — ластик
**бетте** — закончилось, завершилось
**биек** — высоко; высокий
**бии** — пляшет, танцует
**бик** — очень, весьма
**билге I** — отметка
**билге II** — признак предмета
**бирә** — даёт
**бирем** — задание
**бит I** — лицо
**бит II** — страница
**биш** — пять
**бишәү** — пятеро
**бишенче** — пятый
**бишле** — пятёрка
**бияләй** — варежка, варежки
**боз** — лёд
**бозау** — телёнок
**бозлавык** — гололедица
**болын** — луг
**болыт** — туча
**болытлы** — облачно
**борчак** — горох
**борчылу** — беспокойство
**борын** — нос
**борыч** — перец
**ботка** — каша
**бөек** — великий
**бөҗәк** — насекомое
**бөре** — почка
**бөтен** — весь, целый
**бу** — это
**буенча** — по
**була** — бывает
**булыша** — помогает
**буран** — буран, вьюга

**бүген** — сегодня

**бүләк** — подарок

**бүләк итә** — дарит

**бүлергә** — делить

**бүлмә** — комната

**бүре** — волк

**бүрек** — шапка

**бүтән** — другой

## В

**вак** — мелкий

**вакыт** — время

**вата** — разбивает

**Ватан** — Родина

**ватык** — разбитый

**ватылган** — разбито

## Г

**гаеп** — вина

**гаилә** — семья

**гафу ит(егез)** — извини(те)

**гомер** — жизнь

**гөбәдия** — губадия

**гөл** — комнатный цветок

**гөлҗимеш** — шиповник

**гөмбә** — гриб

## Д

**да (дә)** — тоже

**дару** — лекарство

**даруханә** — аптека

**дәрес** — урок

**дәреслек** — учебник

**дәфтәр** — тетрадь

**ди** — говорит

**дөге** — рис

**дөрес** — правильно

**дуңгыз** — свинья

**дус** — друг

**дуслык** — дружба

**дүрт** — четыре

**дүртәү** — четверо

**дүртле** — четвёрка
**дүшәмбе** — понедельник

# Е

**егерме** — двадцать
**егыла** — падает
**ел** — год
**елан** — змея
**елга** — река
**елмая** — улыбается
**ел фасылы** — время года
**елый** — плачет
**ерак** — далеко
**еш** — часто

# Җ

**җавап** — ответ
**җавап бирә** — отвечает
**җанвар** — зверь
**җәен, җәй көне** — летом
**җәй** — лето
**җәнлек** — зверь
**җиде** — семь
**җил** — ветер
**җиләк** — ягода
**җилкә** — плечо
**җимеш** — плод
**җимлек** — кормушка для птиц
**җиңел** — легко; лёгкий
**җир** — земля
**җитә I** — наступает
**җитә II** — хватает
**җитмеш** — семьдесят
**җомга** — пятница
**җөмлә** — предложение
**җыештыра** — убирает, прибирает
**җылы** — тепло; тёплый
**җылыта** — греет
**җыр** — песня
**җырлый** — поёт
**җыя** — собирает

## З

**заманча** — современный
**зарарлы** — вредный
**зәңгәр** — синий, голубой
**зинһар** — пожалуйста
**зур** — большой
**зурлар** — взрослые

## И

**игътибар** — внимание
**Идел** — Волга
**иҗек** — слог
**икән** — оказывается
**икәү** — вдвоём
**ике** — два
**«ике»ле** — двойка
**ил** — страна
**илле** — пятьдесят
**инеш** — ручей
**иң** — самый
**ипи** — хлеб
**иптәш** — товарищ
**иртә** — утро
**иртәгә** — завтра
**иртән** — утром
**иртәнге аш** — завтрак
**иртәрәк** — пораньше
**ис** — запах
**исә** — дует
**исәнме(сез)** — здравствуй(те)
**искиткеч** — изумительный
**истәлек** — воспоминание
**ит** — мясо
**итәк** — юбка
**итек** — сапоги, сапог
**ишек** — дверь

## Й

**йоклый** — спит
**йокы** — сон
**йокыдан тора** — встаёт
**йомран** — суслик

**йомшак** — мягко; мягкий
**йомырка** — яйцо
**йон** — шерсть
**йорт** — дом
**йөгерә** — бежит, бегает
**йөз** — сто
**йөзә** — плывёт, плавает
**йөзем** — изюм
**йөрәк** — сердце

# К

**кабак** — тыква
**кабатлый** — повторяет
**кавын** — дыня
**кадерле** — дорогой
**кадәр** — до
**каз** — гусь
**казый** — копает
**кайбер** — некоторый
**кайда?** — где?
**каймак** — сметана
**кайнар** — горячий
**кайсы?** — который?
**кайта** — возвращается
**кайчан?** — когда?
**кайчы** — ножницы
**канат** — крыло
**каплый** — покрывает, закрывает
**капчык** — мешок
**кар** — снег
**кара** — чёрный
**карабодай** — гречка
**карбыз** — арбуз
**кара карга** — грач
**карлыган** — смородина
**карлыгач** — ласточка
**карт** — старый; старик
**карчык** — старуха
**каршылый** — встречает
**каршында** — перед
**карый** — смотрит; ухаживает
**кат** — этаж

**катык** — катык
**кача** — прячется
**кашык** — ложка
**кая?** — куда?
**каян?** — откуда?
**котлый** — поздравляет
**кош** — птица
**кояш** — солнце
**кояшлы** — солнечный
**кәбестә** — капуста
**кәеф** — настроение
**кәҗә** — коза
**кәрзин** — корзина
**кәшәкә** — клюшка
**кебек** — как
**кем?** — кто?
**кемгә?** — кому?
**кемдер** — кто-то
**кемне?** — кого?
**кемнеке?** — чей?
**кемнең?** — кого? чей?
**кер I** — бельё
**кер II** — заходи, входи
**керә** — заходит, входит
**керергә мөмкинме?** — можно войти?
**керпе** — ёж
**кесәл** — кисель
**кечкенә** — маленький
**кеше** — человек
**кибет** — магазин
**киенә** — одевается
**киеп карый** — примеряет
**килә** — приходит, идёт (сюда)
**килешә** — идёт, подходит (об одежде)
**кинәт** — вдруг
**киң** — широкий
**киңәш** — совет
**кирәк** — нужно, надо
**кисә** — режет
**китап** — книга
**китә** — уходит
**кич** — вечер
**кичә** — вчера

**кич белән** — вечером
**кичке аш** — ужин
**кишер** — морковь
**кия** — надевает
**коела** — осыпается
**коена** — купается
**койрык** — хвост
**колак** — ухо
**колын** — жеребёнок
**корт** — червь
**котлау** — поздравление
**көз** — осень
**көймә** — лодка
**көлә** — смеётся
**көн** — день
**көндәлек** — дневник
**көндез** — днём
**көндезге аш** — обед
**көрәк** — лопата
**көрәшә** — борется
**көтә** — ждёт
**көчле** — сильный
**куе** — густо; густой
**кул** — рука
**кулъяулык** — носовой платок
**курка** — боится
**куркак** — трусливый
**кушарга** — прибавить
**куя** — ставит, кладёт
**куян** — заяц
**күбәләк** — бабочка
**күгәрчен** — голубь
**күз** — глаз
**күзлек** — очки
**күл** — озеро
**күлмәк** — платье, рубашка
**күмер** — уголь
**күнегү** — упражнение
**күңелле** — весело; весёлый
**күп** — много
**күпме?** — сколько?
**күрше** — сосед
**кыз** — девочка

**кыздыра** — печёт (солнце)
**кызык** — интересно; интересный
**кызыл** — красный
**кыйбат** — дорого; дорогой
**кыңгырау** — звонок
**кыр** — поле
**кырык** — сорок
**кыска** — коротко; короткий
**кычыткан** — крапива
**кыш** — зима
**кыш көне, кышын** – зимой
**кыяр** — огурец

## Л

**лалә** — тюльпан
**ләкин** — но, однако

## М

**май** — масло
**мактый** — хвалит
**матур** — красиво; красивый
**мәкаль** — пословица
**мәктәп** — школа
**мәтрүшкә** — душица
**ме́нә** — вот
**менә́** — поднимается
**мең** — тысяча
**миләш** — рябина
**милләт** — нация
**милли** — национальный
**мин** — я
**мине** — меня
**минеке** — мой
**минем** — мой, у меня
**миңа** — мне
**мич** — печь
**монда** — здесь
**мөмкин** — можно
**муен** — шея

# Н

**начар** — плохой

**нәрсә?** — что?

**нәрсәдер** — что-то

**нәрсәнең?** — чего?

**нечкә** — тонкий

**ни?** — что?

**нигә?** — зачем?

**нинди?** — какой?

**ничә?** — сколько?

**ничәнче?** — который?

**ничек?** — как?

**ни өчен?** — почему?

**нишләде?** — что сделал?

**нишләмәде?** — что не сделал?

**нишли?** — что делает?

**нокта** — точка

# О

**оек** — чулки

**оекбаш** — носок, носки

**озак** — долго

**озын** — длинный

**он** — мука

**онык** — внук, внучка

**оныта** — забывает

**оста** — мастер

**оча** — летит

**очрашу** — встреча

**очучы** — лётчик

**ошый** — нравится

**оя** — гнездо

# Ө

**өй** — дом

**өйрәнә** — учится

**өлкән** — старший

**өрә** — лает

**өрек** — урюк

**өстәл** — стол

**өсте** — поверхность

**өстендә** — на поверхности

**өтер** — запятая

**өч** — три

**өчәү** — втроём

**өчен** — для

**өченче** — третий

**өчле** — тройка

**өчпочмак** — треугольник

# П

**пәнҗешәмбе** — четверг

**пәрәмәч** — перемяч

**песи** — кошка

**песнәк** — синица

**печән** — сено

**пешерә** — варит

**пеште** — сварилось

**пилмән** — пельмени

**поши** — лось

**пөхтә** — аккуратно; аккуратный

**пылау** — плов

**пычак** — нож

**пычкы** — пила

**пычрак** — грязно; грязный

**пыяла** — стекло; стеклянный

# Р

**рәсем** — рисунок

**рәсем ясый** — рисует

**рәхәт** — приятно, отрадно

**рәхим ит(егез)!** — добро пожаловать!

**рәхмәт** — спасибо

**риза** — согласен, согласна

**рөхсәт** — разрешение

**русча** — по-русски

# С

**сабын** — мыло

**савыт-саба** — посуда

**саен** — каждый
**саескан** — сорока
**сай** — мелко; мелкий
**сайлый** — выбирает
**саклый** — охраняет, бережёт
**сала** — кладёт; снимает
**салават күпере** — радуга
**салкын** — холодно; холодный
**сан** — число
**санамыш** — считалка
**сандугач** — соловей
**саный** — считает
**саран** — скупой
**сары** — жёлтый
**сарык** — овца
**сарымсак** — чеснок
**сата** — продаёт
**сатучы** — продавец, продавщица
**сатып ала** — покупает
**сау бул(ыгыз)** — до свидания
**сәгать** — часы
**сәлам** — привет
**сәламәтлек** — здоровье
**сәнәк** — вилы
**сәхнә** — сцена
**сез** — вы
**сезгә** — вам, к вам
**сезне** — вас
**сезнең** — ваш
**сеңел** — младшая сестра
**сибә** — поливает
**сигез** — восемь
**сигезенче** — восьмой
**сикерә** — прыгает
**сиксән** — восемьдесят
**сине** — тебя
**синең** — твой, у тебя
**сиңа** — тебе
**сишәмбе** — вторник
**соклану** — восхищение
**сорау** — вопрос

**сорау бирә** — задаёт вопрос

**соң I** — поздно

**соң II** — после

**сөекле** — любимый

**сөйли** — рассказывает

**сөртә** — вытирает

**сөт** — молоко

**су** — вода

**суган** — лук

**сузык аваз** — гласный звук

**сүз** — слово

**сүзлек** — словарь

**сыер** — корова

**сыерчык** — скворец

**сызлый** — болит

**сызыклы** — в линейку

**сыйныф җитәкчесе** — классный руководитель

# Т

**таба (өйгә таба)** — по направлению (к дому)

**табигать** — природа

**табын** — накрытый стол

**табышмак** — загадка

**тавык** — курица

**такта** — доска

**тама** — капает

**тамак** — горло

**тамак тую** — насытиться

**тамчы** — капля

**тамыр** — корень

**таныш** — знакомый

**тап** — пятно

**тапкырларга** — умножать

**тар** — узкий

**тарак** — расчёска

**тарата** — раздаёт, разбрасывает

**тарих** — история

**тартык аваз** — согласный звук
**татар** — татарин; татарский
**тату** — дружно
**тау** — гора
**таш** — камень
**тәбәнәк** — низкий
**тәлинкә** — тарелка
**тәмле** — вкусно; вкусный
**тәнәфес** — перемена
**тәрбияле** — воспитанный
**тәртип** — порядок
**теге** — тот
**тегүче** — портной
**тел** — язык
**телим** — желаю
**теш** — зуб
**тиен I** — белка
**тиен II** — копейка
**тиз** — быстро
**тиздән** — скоро
**тик** — однако
**тимераяк** — коньки
**тоз** — соль
**тозлы** — солёный
**токмач** — лапша
**томшык** — клюв
**тора I** — встаёт, стоит
**тора II** — живёт
**тота** — ловит
**төзәтә** — исправляет
**төлке** — лиса
**төн** — ночь
**төрле** — разный
**төс** — цвет
**төсле** — цветной
**төш** — сон
**төшә** — спускается
**туган** — родной
**туган көн** — день рождения
**тугыз** — девять
**тузан** — пыль
**тук** — сыто; сытый
**тукран** — дятел

**тукталыш** — остановка
**туңа** — замерзает, мёрзнет
**туп** — мяч
**түбәтәй** — тюбетейка
**түгәрәк** — круглый
**түли** — платит
**тыңлый** — слушает
**тырыс** — корзина
**тырыш** — старательный

# У

**уен** — игра
**уенчык** — игрушка
**уз** — проходи, входи
**уйный** — играет
**укучы** — ученик
**укый** — читает; учится
**укыта** — учит
**укытучы** — учитель
**ул I** — он (она, оно)
**ул II** — сын
**ун** — десять
**уналты** — шестнадцать
**унбер** — одиннадцать
**унбиш** — пятнадцать
**ундүрт** — четырнадцать
**унҗиде** — семнадцать
**унике** — двенадцать
**унөч** — тринадцать
**унсигез** — восемнадцать
**унтугыз** — девятнадцать
**уңган** — умелый
**уңыш I** — успех, удача
**уңыш II** — урожай
**урман** — лес
**урнашкан** — находится
**урындык** — стул
**усал** — злой
**ут** — свет, огонь
**утыз** — тридцать
**утыра** — сидит
**уяна** — просыпается

## Ү

**үбә** — целует

**үзе** — сам (сама, само)

**үлә** — умирает

**үлән** — трава

**үлчи** — взвешивает

**үрдәк** — утка

**үсә** — растёт

**үстерә** — выращивает

**үтә** — проходит

## Ф

**файда** — польза

**файдалы** — полезно; полезный

**фил** — слон

## Х

**хайван** — животное

**халык** — народ

**хат** — письмо

**хата** — ошибка

**хатын** — жена

**хатын-кыз** — женщина

**хәерле көн!** — добрый день!

**хәзер** — сейчас

**хәлләр ничек?** — как дела?

**хәреф** — буква

**хикәя** — рассказ

**хөрмәтле** — уважаемый

**хуҗа** — хозяин

**хуш(ыгыз)!** — прощай(те)!

**хуш киләсез!** — добро пожаловать!

## Һ

**һәйкәл** — памятник

**һәм** — и

**һәр** — каждый

**һәркем** — каждый (человек)

# Ч

**чаба** — скачет

**чакыра** — зовёт, приглашает

**чакыру** — приглашение

**чалбар** — брюки

**чана** — сани

**чаңгы** — лыжи

**чәкчәк** — чак-чак

**чәнечке** — вилка

**чәршәмбе** — среда

**чәч** — волос

**чәчә** — сеет

**чәчәк** — цветок

**чәчәк ата** — цветёт

**чебен** — муха

**чеби** — цыплёнок

**чикләвек** — орех

**чир** — болезнь

**чирәм** — трава

**чиста** — чисто; чистый

**чисталык** — чистота

**чия** — вишня

**чөгендер** — свёкла

**чөнки** — потому что

**чуртан** — щука

**чүкеч** — молоток

**чүлмәк** — горшок

**чүпрәк** — тряпка

**чыга** — выходит

**чык** — выйди

**чынаяк** — чашка

**чыпчык** — воробей

**чыршы** — ель

# Ш

**шагыйрь** — поэт

**шакмаклы** — в клетку

**шалкан** — репа

**шалтырата** — звонит

**шат** — рад

**шатлана** — радуется

**шаян** — весёлый

**шәһәр** — город

**шигырь** — стихотворение

**шикәр** — сахар

**шимбә** — суббота

**шуа** — катается

**шугалак** — каток

**шук** — шустрый

**шул** — тот

**шуңа күрә** — поэтому

**шушы** — это

# Э

**эз** — след

**эзли** — ищет

**элә** — вешает

**элгеч** — вешалка

**элек** — давно

**энә** — игла

**эне** — младший брат

**энҗе чәчәк** — ландыш

**эре** — крупный

**эри** — тает

**эссе** — жарко; жаркий

**эт** — собака

**эчә** — пьёт

**эчәсе килә** — хочется пить

**эчендә** — внутри

**эш** — работа

**эшли** — работает

**эшче** — рабочий

# Ю

**ю** — мой

**юа** — моет

**югалта** — теряет

**юк** — нет

**юл** — дорога

**юмарт** — щедрый

**юына** — умывается

# Я

**ява** — идёт (снег, дождь)

**явыз** — злой

**явымсыз** — без осадков

**яз** — весна
**яза** — пишет
**яз көне, язын** — весной
**як (туган як)** — сторона (родная земля)
**якты** — светлый
**якын** — близко; близкий
**як-якка** — по сторонам
**ялгыш** — ошибочно
**ял итә** — отдыхает
**ялкау** — ленивый
**ял көне** — выходной
**яме** — ладно
**ямьле** — прекрасно; прекрасный
**ямьсез** — некрасиво; некрасивый
**яна** — горит
**янында** — возле, около
**яңа** — новый
**яңгыр** — дождь
**яр** — берег
**ярамый** — нельзя
**ярата** — любит
**ярдәм** — помощь
**ярма** — крупа
**ярыш** — соревнование
**ясый** — делает, рисует
**ята** — лежит
**ятлый** — учит наизусть
**яулык** — платок
**яфрак** — лист
**яфрак яра** — распускает листья
**яхшы** — хорошо; хороший
**яшел** — зелёный
**яшелчә** — овощ
**яши** — живёт
**яшь I** — год
**яшь II** — молодой
**яшь III** — слеза
**яшьләр** — молодёжь

# Эчтәлек

**Яңа уку елы котлы булсын!**

1–23 нче дәресләр ............................... 4

**Минем туган илем**

24–37 нче дәресләр ............................... 27

**Туган як табигате**

38–51 нче дәресләр ............................... 41

**Хайваннар һәм кошлар дөньясында**

52–64 нче дәресләр ............................... 59

**Сәламәтлек — зур байлык**

65–80 нче дәресләр ............................... 72

**Минем дусларым**

81–86 нчы дәресләр ............................... 90

**Безнең шөгыльләр**

87–91 нче дәресләр ............................... 96

**Минем бер көнем**

92–98 нче дәресләр ............................... 102

**Без сәяхәт итәбез**

99–102 нче дәресләр ............................... 111

**Сүзлек** ............................... 118

Учебное издание
Серия «Күңелле татар теле»

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна
**Гиниятуллина** Лейсан Адиповна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**4 класс**

Учебник для образовательных организаций начального общего образования

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р.З. Хайдарова,*
*Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина*
Продюсер проекта *А.М. Ганиев*
Руководитель проекта *А.Т. Низамеева*
Художественный руководитель *С.В. Киатров*
Вёрстка *Д.И. Бариев*
Технический руководитель *И.М. Низаметдинов*
Редакторы *Ф.Ш. Ахметзянова, Г.М. Ахметзянова*
Художники *А.Р. Ромашова, Н.К. Авдеева*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 20.08.2024. Формат 84x108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная».
Печать офсетная. Уч.-изд. л. 9.5. Тираж экз. Заказ №

Издательство «Татармультфильм».
420034, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
**www.tatarmultfilm.ru**

**Издательство «Татармультфильм»**
разрабатывает и выпускает:

— учебники,
— мультимедийные пособия,
— методические пособия,
— рабочие тетради,
— художественно-анимационные издания,
— интерактивные приложения.

**www.tatarmultfilm.ru**

Дополнительные материалы по изучению татарского языка и литературы для классных и внеурочных занятий на сайте
**tatarschool.ru**





Школьный учебник



ISBN 978-5-906508-01-0

издательство
«Татармультфильм»